ЭЗЛӘГӘН ТАБАР

Татарстан – эш эзләү өчен ил күләмендә иң отышлы төбәк

> 7

САГЫНДЫРА АРМИЯ

Ул безне яшәргә, нык булырга, дөньяны танып-белергә өйрәтте

> 7

АВЫРТКАН ҖИР

Балаларының «папа», «мама» дигәненә риза булып утырган татарга шаккатам...

> 8

АТЛЫ БАЛАЛАР

Әтиләре нәсел дәвамчыларына узенчәлекле бүләк ясаган

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 23 (29183) | Чәршәмбе | 21 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ҮЗ КУЛЫҢДА

БЕЛГЕЧЛӘР ХАЛЫКНЫ СӘЛАМӘТЛЕККӘ ИГЪТИБАРЛЫРАК БУЛЫРГА ӨНДИ

Борчыган мәсьәлә

Узган ел Татарстанда 26 тапкыр (!) йөрәк күчереп утырткannар. Берничә көн элек моңдый катлаулы операцияне тәүге тапкыр Чаллыда ясадылар. Бер ел эчендә республикада уртача гомер озынлыгы да арткан. Быел Татарстанда яшүсмерләр сәламәтлегенә игътибарны арттырып, мәкерле чирләрне кисәтү буенча да эшне көчәйтмәкчеләр. Хөкүмәт йортында узган брифингта шул хакта сөйләштеләр.

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, узган ел республикада бер мең кешегә 10,7 үлем-китем очраклары туры килгән. Идел буе төбәкләре арасында иң кечкенә сан бу. Россия төбәкләре арасында исә Татарстан ул яктан 19 нчы урынга чыккан. Узган ел республикада уртача гомер озынлыгы да, артып, 75,38 яшь тәшкил иткән. Министр «Сәламәтлек» илкүләм проекты кысасында билгеләнгән эшләрнең быел да уңышлы гына дәвам итәчәгенә өметләнә.

Быел сәламәтлек саклау тармагының беренче звеносын яңарту буенча төбәк проекты кысаларында 2,12 млрд сум акча тотылачак. Узган ел бу максатка 2,49 млрд сум бүленгән булган. Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, былтыр 27 объект төзелгән. Быел тагын 29 бина сафка басачак. Моннан тыш, Татарстанда 105 объект төзекләндереләчәк. Чагыштыру өчен: узган ел шундый 117 объект яңартылган булган.

– Сырхаухәнә һәм хастаханәләрне җиһазландыру эше дә дәвам итәчәк. Узган ел Татарстанда 1,9 мең медицина оешмасына яңа техника кайтарылган булса, быел дүрт тапкыр күбрәк: барлыгы 8,8 мең дәвалау оешмасы яңа техникалы булачак, – дип ачыклык кертте министр.

Узган ел республикада барлыгы 2,6 мең яман шеш очраклары ачыкланган. Шуларның 1,9 меңе беренче-икенче стадиягә табылган. Чагыштыру өчен: 2022 елда республикада 2,5 мең яман шеш очрагы теркәлгән булган. Шуларның 1,7 меңе башлангыч чорда ачыкланган.

– Яман шешкә каршы көрәш юнәлешендә уңай узгәрешләр бар. Әмма тынычланырга иртәрәк.

ru.freepik.com

Үлем-китемгә китергән иң төп авырулар исемлегендә элеккечә үк йөрәк-кан тамырлары авырулары, яман шеш очраклары кала бирә. Бөтен ил, дөнья күләмендә шул хәл, – дип искәртте Марсель Миңнуллин.

Татарстанның штаттан тыш баш онкологы Эдуард Нагуманов кеше гомеренә куркыныч тудырган мәкерле чирләрне кисәтүнең иң нәтиҗәле юлы дип диспансеризация узуны атый. Аның барышында, әйтик, кеше яман шешнең биш төре – күкрәк, аналык муентыгы, эчәклек, мәни бизе, тире яман шешенә тикшерү уза ала.

– Әгәр кеше чир 3–4 нче стадиягә җиткәч килә икән, бу очракта инде берникди югары технологияләр дә ярдәм итмәскә мөмкин. Шуңа күрә чир никадәр иртәрәк табылса, аны тулысынча җиңү ихтималы да шулкадәр зуррак, дип гел искәртеп киләбез. Беренче ике стадиядә табылса, яман шешне дәвалау ихтималы 75–98 процент тәшкил итә. Өченче-дүртенче стадиядә исә чирне җиңү түгел, азмасын дип күзәтеп тору турында сүз бара.

Шуңа күрә яман шешне булдырмау өчен, вакытында диспансеризация узарга кирәк, – ди белгеч.

Республика балалар клиник хастаханәсенең Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә узган ел 3,5 мең сабый дәваланган. Бер ел эчендә бирегә арка миен күчереп утырту буенча 10 катлаулы операция ясалган. Әлеге үзәк 2021 елда ачылды. Бүген ул Идел буе федераль округындагы бердәнбер Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәге санала. Быел Татарстанда яшүсмерләр сәламәтлегенә дә игътибарны арттырмакчылар.

Күрел торабыз: соңгы елларда Татарстан иң эре трансплантология үзәкләренең берсенә әверелде. Моңа кадәр Мәскәү, Санкт-Петербургта ясалган моңдый катлаулы операцияләр хәзер үзебездә ясала. Әле бу көннәрдә генә Чаллы табиблары беренче тапкыр кешенең йөрәген күчереп утырткан.

Ахыры 7 нче биттә >

Үзеңне үзең тыю

Дәүләт Думасы кредит алуга үзенә үзен тыю билгеләү хокукы турында закон проектын соңгы укылышта кабул иткән.

Дума Рәисе Вячеслав Володин әйтүенчә, закон, персональ мәгълүматларны урлап, теге яки бу кеше исеменә кредитлар һәм микрозаемнар рәсмиләштерүче мошенникларрдан котылу мөмкинлеге бирачәк.

Ләкин тыю ипотекага, автокредитка, шулай ук дәүләт ярдәме нигезендә уку өчен бирелә торган кредитка кагылмый. Үзеңне кредит алудан Дәүләт хезмәтләре порталында, Күпфункцияле үзәкләрдә һәм банкларда тыярга мөмкин булачак.

Яңарталар

Татарстанда 18 районда, шул исәптән Казанда су белән тәэмин итү системасын яңарту күздә тотыла. Кайбер урыннарда яңа торбалар сузарга, кайберләрендә реконструкцияләргә туры киләчәк. «Реальное время» хәбәренә караганда, моның өчен 264,7 миллион сум бирелә.

Инде әйткәнебезчә, контракт кысасында 18 районда эшләр алып барылачак. Ъында реконструкция эшләре каралган. Шулай итеп, Актаныш, Арча, Балтач, Зөй, Кайбыч, Минзәлә, Питрәч, Саба, Сарман һәм башка районнарда су белән тәэмин итү яхшырачак.

Барлык эшләрне быел 1 декабрьгә кадәр төгәлләргә кирәк булачак. Бу максатка акча республика бюджетыннан бирелә.

Җәй нинди булыр?

Быелгы җәй метеокүзәтүләр тарихында иң эссесе булырга охшап тора. Синоптиклар мәгълүматлары буенча, инде июнь аенда үк эссе һава урнашып, нормадан чама белән 7 градуска югарырак булачак.

«Известия» телеканалы хәбәренә караганда, Мәскәү, Тверь, Калуга кебек шәһәрләрдә һава температурасының рекордлы +35 градуслы күрсәткечкә житүе күздә тотыла. Шулай ук Идел буе төбәкләрендә (димәк, Татарстанда да), Уралда, Төньяк Кавказ республикаларында, Себер һәм Ерак Көнчыгышта да температура рекордлары көтелә.

Белгечләр әйтүенчә, моның сәбәбе Эль-Ниньо күренешенә (Тын океанның экваторга якын өлешендә су өсләгенең бик нык җылынуы) бәйле.

Суз уңаеннан, быелгы гыйнвар дөньяда һава торышын күзәтү тарихында иң җылысы икән. Климатның үзгәрүе буенча Европа хезмәте мәгълүматларына караганда, җир өслегендә һава температурасы уртача +13...+14 градус булган. 2020 елның гыйнвар ае белән чагыштырганда бу күрсәткеч 0,12 градуска зуррак.

Спорт кына түгел бу

Уйлап уйна

Тарихи вакыйга. Казандагы фиджитал-үзәк ачылышын шулай дип бәяләделәр. Аны федераль кунаклар хәер-фатихасы белән ачтылар. Бу үзәктә ниләр урнашкан? Яңа ачылган бинада без дә булып кайттык.

Сүз уңаеннан, фиджитал-үзәкне махсус «Киләчәк уеннары» халыкара турниры өчен сафка бастырдылар. Бу – Россиядәге өченче шундый үзәк. Аны булганнарның иң яхшысы дип атадылар.

Фиджитал-үзәк ачылышына Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко һәм Россия спорт министры Олег Матыцин килде. Үзәктәге шартлар белән танышып, алар яңа бинадагы беренче кунаклар – киберспортчылар хәлен белешеп, башкарган эшкә бәя бирде.

Фиджитал-үзәк Универсиада авылы территориясендә (Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты базасында) сафка басты. Ике зонадан тора (спортның гадәти төрләре һәм киберспорт төрләре өчен). Киберспорт өлешендә 20ләп компьютер, виртуаль чынбарлык зонасы һәм уен зонасы урын алган. Хәзерге вакытта бирегә 80ләп кеше шөгыльләнә. Араларында университет шәкертләре дә бар. Шулай ук төрле разрядтагы киберспортчылар да.

Дмитрий Чернышенко Казанда фиджитал-үзәк ачылуын тарихи вакыйга дип атады.

– «Киләчәк уеннары» – бөтенләй яңа формат, ул безнең Президентыбыз Владимир Путин указы бу-

«Татар-информ»

енча илебездә дә, дөньяда да беренче тапкыр үткәрелә. Фиджитал хәрәкәте бөтен дөньяны колачлады, – диде ул, үзәкне тантаналы төстә ачканнан соң.

– Казанда университет базасында фиджитал-үзәк барлыкка килү аерым мәгънәгә ия. Әлегрәк киберспорт дип аталган, хәзер инде фиджитал спорт дигән факультет кысасында махсус белгечләр әзерләнәчәк. Алар исә, кешенең физик ягы да, виртуаль дөньядагы сәләтләре дә үсеш алсан өчен, методик стандартлар әзерләячәк. Киберспорт юнәлешендә генә яисә гадәти спортта гына түгел, ике яклы үсеш булсын өчен кирәк бу. Мондый әзерлек үзәкләре нәкъ шул мөмкинлекне бирә. Әйтик, яшьләр бирегә Россияда барлыкка килгән компьютер программалары нигезендә тактик көрәш ярышын виртуаль дөньяда узләштерә, аннан лазертаг ярышында аны чынбарлыкта башкара.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстан Язучылар берлеге рәисе:

Без – башкортлар белән тугандаш халык. Татарлар башкортлар белән гомер буе тату яшәгән. Тарихта татар-башкорт сугышы, орышы беркайчан булмаган. Ике милләт арасына таяк тыгу ул – шуннан карьера ясарга тырышу. Кайберәүләр ясадылар да. Кайберләре әле ясап өлгермәгән.

(«Интертат»)

РОССИЯДӘ – АКЧА

Һәр икенче россияле бернәрсәгә дә тоту ихтыяҗы булмаган ирекле акчасын банкка сала икән. Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре әнә шуны ачыкланган.

АКЧАНЫ КАЙДА САКЛАУ ЯХШЫРАК?

- 47% >> банкта
- 27% >> банктагы акчаны алырга тели
- 26% >> җавап бирергә кыенсына

Тагын өч кенә уен

«Ак барс» плэй-офф кадәр буласы соңгы 3 очрашуның барысын да Казанда Спорт сараенда уздырачак. Зиннәтулла Билалетдинов хоккейчылары 21 февральдә – «Локомотив», 24ендә – «Амур», 26сында исә «Адмирал» белән көч сынаша. Әлегә безнекеләр Көнчыгыш конференциясенең турнир таблицасында 4 нче урында урнашкан. «Ак барс»ның 80 очкосы бар. 5 нче урындагы «Автомобилист» 2 очкога калыша. Казан һәм Екатеринбург командалары плэй-оффның беренче өлешендә бер-берсенә каршы уйнарга мөмкин. Әлегә беренче очрашуның кайда буласы билгеле түгел.

«Нефтехимик» исә, сигезенче урынга күтәрелеп, плэй-оффка соңгы юлламаны узенеке итү өчен көрәшә. Әмма Түбән Кама командасы Хабаровск «Амур»ыннан 4 очкога калыша. Шулай итеп, якташларыбызның плэй-оффка чыгу ихтималы зур түгел. Узган ел Гагарин Кубогы өчен көрәшнең беренче өлешендә «Ак барс» белән «Нефтехимик» узара уйнап, Казан командасы өстен чыккан һәм финалга кадәр барып җиткән иде.

ak-bars.ru

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СӨЙЛӘШӘЛӘР ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ

Үткән атнада алтмышынчы тапкыр Куркынычсызлык буенча Мюнхен конференциясе булып үтте. Кырыклап дәүләт һәм хөкүмәт җитәкчесе, туксаннан артык тышкы эшләр һәм оборона министрлары катнашкан бу җыенга мәгълүм сәбәпләр аркасында Россиянең рәсми вәкилләре чакырылмады.

АКШның Дәүләт секретаре Антони Блинкен: «Халыкара мөнәсәбәтләр системасында син сөйләшүләр өстәле янында утырмыйсың икән, димәк, син – менюда», – дип белдерсә дә, конференциядә төшенкелек хөкем сөрде, диделәр. Украина белән конфликтта нәкъ шул ук көннәрдә Россия тактик уңышларга ирешә, Киевны корал белән тәэмин итү мәсьәләсе хәл ителми, чөнки Европа дәүләтләренең җитештерү куәтләре җитәрлек түгел, Америкада исә конфликтны финанслау мәсьәләсе буенча кайнар бәхәсләр бара. Мәскәү берничә тапкыр сөйләшүләр өстәле тәкъдим итеп караса да, Көнбатышта колакларына мамык тутырдылар.

Европада җәмәгатьчелек фикере дә үзгәрде дигән хәбәрләр килә. Бер ел элек көнбатышлылар Украина контрһөҗүменә зур өметләр баглаган булса, хәзер аларны бөтенләй башка проблемалар борчый. Фермерларның һаман да тынмаган протесты – шуның бер дәлиле. Халыкара мөнәсәбәтләр системасында Көнбатыш бердәнбер өстенлек итүче көч булудан туктады, бу да – факт. АКШ һәм европалылар коалициясе күпме генә тырышмасын, Кызыл диңгездә уен кагыйдәләрен Йәмән урнаштыра. Шуны да истә тотарга кирәк: бүген Йәмән икегә бүленгән. Бер өлеше америкалылар кырында уйный, радикаль икенче өлеш Кызыл диңгезне ракеталар белән коендыра. Үткән тәүлекләрдә генә алар берничә корабка зыян салды, Британиянең Rubymar корабы су төбенә үк китте. Рәсми көнбатышлылар тарафыннан якланган Израиль агрессиясе бүген 52 дәүләт гаризасы нигезендә БМОның Халыкара судында тикшерелә. Шуны ассызыклыйк: судта Израиль соңгы айларда кылган вәхшилекләре өчен генә түгел, 1967 елдан бирле алып барган талауларда гаепләнә.

Көнбатышның Кытай белән мөнәсәбәтләре дә яхшы түгел. Кытайның тышкы эшләр министры Ван И Мюнхен конференциясендә катнашты катнашуын, әмма алар көнбатышлылар позициясен яклап ук бетерми. Күк асты иле белән икътисад сугышы яңа югарылыкка күтәрелергә вәгъдә итә. The Financial Times АКШның Пекинны халыкара базарларда товарларга бәя төшереп, үз сәнәгате проблемаларын хәл итүдә гаепләве һәм моңа каршы чаралар күрәчәген әйтеп кисәтүе турында яза. Күрәбез: конфликт күп кишәрлекләрдә бара һәм киләчәктә кемнең өстәл янында, кемнең менюда булачагын әйтү кыен. Бер нәрсә мәгълүм: конфликт төенләнгәнче, аны чишсәң яхшырак.

Россиядә

КИБЕТКӘ ТҮГЕЛ, БАНККА БАРЫРГА

Үткән җомгада Россия Үзәк банкының чираттагы утырышы булды. Утырыштан берәү дә сенсация көтмәде: төп ставка күтәрелмәс тә, төшерелмәс тә, диделәр. Сер түгел: бизнес та, кредит хисабына көн күрергә гадәтләнгән халык та ставканың төшерелүен тели. Бүген үк булмаса, алдагы айларда вазгыять йомшармасмы дип көтә. Процент зуррак булган саен, бурычларны түләү кыенлаша.

Хәзерге икътисад моделе исә бурычка яшәүне күз алдында тота. Шуннан башка булмый дип саный. Банкирлар тегермәненә су коя торган бу вазгыять хәвефле. Кешеләр алны-артны карамый кредит җыя да ахыр чиктә ярык тагарак алдында кала: бурычларны кайтару мөмкин түгел. Бишкә кадәр кредит җыючылар саны арта. Кредитларын кайтара алмаучылар саны тагын да зуррак тизлектә үрчи. Суд приставлары федераль хезмәте үткән елда банклар файдасына 24,6 миллион эш каралуын әйтә. Гражданнардан банклар файдасына кайтарылып алынырга тиеш акчаның гомуми күләме 3,26 триллион сумга җиткән. Бер ел эчендә 200 миллиард сумга үскән.

Бик кызыклы вазгыять килеп туа: Үзәк банк, инфляцияне йөгәнлим дип, төп ставканы күтәрә. Халык, инфляция көчәя дип, проценты никадәр генә югары булмасын, кредит җыя. Үзәк банк мантыйгы бер яктан дөрес кебек: төп ставка үскәндә, депозит ставкалары да күтәрелә һәм кешеләр акча тотып кибеткә барасы урынга аны банкларга салырга ашыга. Ихтыяҗ кими һәм бәяләр төшә. Ләкин бу мантыйк Россиядә эшләми. Бердән, ихтыяҗның кимүе бәяләрне төшерми. Икенчел торак базарында ихтыяҗ кимеде, ди рәсми статистика, вәләкин торак бәясе барыбер үсә. Кибетләрдә дә шуңа охшаш хәл. Кешеләр күреп тора: чын инфляция рәсми инфляцияне күпкә узып китә һәм, бәя нинди генә булмасын, кредит хисабына булса да, товар алып калырга ашыга. Банк депозитына акчасы ташып торган катлау гына илтә капиталын.

Аннан соң тагын бер нәрсә бар: кешеләр телефон мошенникларына, кредитка алып, миллионнарны бүләк итә. Элементар дәрәҗәдә фикерләү юк, шулай булгач, нинди мантыйк эшләсен? Әҗәткә җыйган байлык белән гипнозланган халыкны ставка күтәреп кенә айныту мөмкин түгел. Үзәк банк та төшенә моны. Бизнес күпме генә өметләнмәсен, ставканы түбән куарга ашыкмый, чөнки белә: кредит арзанайса, бурыч җыюга хирыслык тагын да артачак.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

КАРА АЛТЫН ЧЫККАН ҖИРДӘ

russia.riamediabank.ru

«Алга таба хәрәкәт итәргә кирәк». «Россия» халыкара форум-күргәзмәсе кысасында узган «Россия энергетикасының тотрыклылыгы һәм лидерлыгы» пленар сессиясендә чыгыш ясаганда, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әнә шулай дип белдерде. Ул республикада тормышка ашырылучы нефть һәм газ химиясе проектлары турында сөйләде.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, Татарстан – илнең нефть чыгаручы төбәге. Бүген республикада елына 35 миллион тоннадан артык кара алтын чыгаралар.

– Бу эш белән 1943 елдан бирле шөгыльләнәбез. Тәүге скважинаны Бөек Ватан сугышы елларында ук бораулаганнар, – диде Татарстан Рәисе. – Шул чордан бирле 3,5 миллиард тонна нефть чыгардык.

Рөстәм Миңнеханов республикада соңгы елларда бу тармакта тормышка ашырылган проектлар турында да сөйләде.

– 2010 елга кадәр бер генә эшкәртү комплексына ия булып, елына 7 миллион тоннага кадәр нефть эшкәртсәк, бүген ике зур комплексыбыз бар, – диде ул.

Татарстан Рәисе 2023 ел нәтиҗәләре буенча, республикада 23,7 миллион тонна углеводород эшкәртелүен дә әйтте. Тирәнтен эшкәртү күрсәткече – 99 процент. «Әлеге заводлар нефть химиклары өчен чимал базасы булып тора. СИБУР төркеменә ике предприятие – «Түбән Кама Нефтехим» һәм «Казаноргсинтез» карый. Бу – илнең 30 процент полимеры һәм 42 процент каучугы дигән сүз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Аның әйтүенчә, безгә алга таба хәрәкәт итәргә кирәк. Фикерен дәвам иттереп, төбәктә тормышка ашырылучы «Этилен-600» проектының 2025 ел башында ук эшли башлаячагын хәбәр итте ул. «Бу хәзерге вакытта «Түбән Кама Нефтехим» җитештергән кадәр этилен булачак, – диде Татарстан Рәисе. – Икенче проект «Казаноргсинтез»да полимерлар җитештерүне киңәйтү».

> Ике проект буенча да эш бара. Аларны тормышка ашыруга СИБУР төркеме былтыр – 50 миллиард сум, быел 70 миллиард сум инвестицияләр җәлеп итте. Барлык планнар да тормышка ашар, дип ышанам.

Моннан тыш, республикада газ химиясе дә үсештә. Бу форсаттан, утырышта «Аммоний» заводын искә алдылар. «Аммоний-2» проекты кысасында, без 2028 елга кадәр азотлы ашламалар җитештерү күрсәткечен ике ярым тапкыр арттырачакбыз», – диде Татарстан Рәисе. Ул республикадагы барлык проектларның дөньякүләм экологик таләпләргә туры китереп тормышка ашырылуын да искәртте.

Туган тел көне белән!

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы Советы Рәисе Ф.Х. МӨХӘММӘТШИНның Халыкара туган тел көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне ихлас күңелдән Халыкара туган тел көне белән котлыйм. Бу истәлекле көнне гамәлгә кую турында карар 1999 елның 17 ноябрендә ЮНЕСКО Генераль конференциясенең 30 нчы сессиясендә кабул ителә һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясы тарафыннан хуплана. Шул вакыттан башлап 21 февральдә Җир шарының барлык тарафларында да тел һәм мәдәниятнең күптөрлелегенә ярдәм итү һәм аны яклау чаралары үткәрелә.

Дөньядагы иң зур «Этнолог» лингвистик белешмәлеге мәгълүматлары буенча, 2022 елда безнең планетада 142 төрле «тел гаиләсе»нә (Җир шарында яшәүче халыкның өчтән икесе шуларның кырыгында сөйләшә) караган 7 меңнән артык тел исәпләнгән. Шуның белән бергә, глобальләшү күренешләренә бәйле рәвештә «тере» телләрнең саны көннән-көн кими бара. Бу дөнья җәмәгатьчелегендә борчу уята, чөнки тел – бер этносның аралашу ысулы гына түгел, ул шулай ук дөньяны кабул итү, аны күзаллау рәвеше, халыкның интеллектуаль үсеше механизмы, буыннан буынга тапшырыла торган матди һәм рухи мирасны, традицияләрне һәм гореф-гадәтләрне саклау инструменты да.

Соңгы тапкыр Халык санын алу күпмилләтле Россия Федерациясендә 190нан артык халык яшәвен күрсәтте. Аларның һәркайсының күпгасырлы үз тарихы, үзенчәлекле мәдәнияте һәм теле бар. Мондый күптөрлелек – безнең уртак байлыгыбыз, бер-берењне рухи һәм мәдәни баетуның көчле чарасы, илнең эчке куәтенең кабатланмас чыганагы.

Халык санын алуга анализ ясаганда, Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институты белгечләре 155 «тере» телне аерып алды. Шуларның 10 процентына югалу куркынычы яный, 60 проценттан артыгы җуелу чигенә җитеп килә һәм бары тик 7 проценты гына тотрыклы дип билгеләп үттеләр. Соңгылары арасында беренче урында – рус теле (111,5 млн кеше), икенче урында татар теле (4,07 млн) тора. Аннары чечен (1,64 млн), башкорт (1,32 млн), авар (0,94 млн) һәм Россия халыкларының башка телләре бу исемлекне дәвам итә.

Хөрмәтле ватандашлар! Билгеле бер әйтемне беразүзгәртеп: «Туган телне ярату гына җитми, аны сакларга кирәк», – дип әйтәбез. Нәкъ менә күптеллелек гармониясенә ирешү, милли мәгариф, әдәбият һәм сәнгатьне үстерү, традицион әхлакый кыйммәтләрне саклау җәмәгать татулыгының һәм граждан тынычлыгының нигезе булып тора. Ил һәм республика җитәкчелеге, шуларны тирәнтен аңлап, бу юнәлештә зур җентекле эш алып бара.

Бүген, Халыкара туган тел көне белән котлап, мин барыгызга да туган телегезне – әни һәм әти, әби һәм бабай телен – өйрәнүегезне һәм анда мөмкин кадәр ешрак сөйләшүегезне телим. Үзегезне халкыгызның бер өлеше дип хис итеп, гаилә кыйммәтләрен саклап, башка этнослар вәкилләренә игътибарлырак һәм түземлерәк булырга, илебезнең иксез-чиксез киңлекләрендә телнең күптөрлелеген ихтирам итәргә һәм аны һәрьяклап ныгытырга чакырам. Барыгызга да нык сәламәтлек, иминлек һәм бәхет телим! Халыкара туган тел көне чын мәгънәсендә Тынычлык, дуслык һәм бер-береңне аңлау бәйрәме булсын!

ДУСЛЫК ХАКЫНА

Йомгак

Эше яңа – бурычы шул ук. Татарстан халыклары ассамблеясы конференциясендә узган өч елга нәтиҗә ясадылар. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алга таба да Ассамблеяны җитәкләвен дәвам итәчәк, башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына исә яңа кеше килде.

Ассамблея үз эченә 262 төбәк һәм җирле оешманы, Халыклар дуслыгы йорты һәм үзәкләренең вәкиллекләрен, Яшьләр ассамблеясын, күпмилләтле якшәмбе мәктәпләрен ала. Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Халыклары ассамблеясы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин узган ел милли-мәдәни автономияләрнең 1879 чара уздырганын әйтте. Парламент башлыгы республикада узган ел булган төп вакыйгаларга тукталып, Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы узганын искә төшерде һәм бездә төрле мәдәниятләрне үстерү өчен шартлар җитәрлек булуын әйтте.

Билгеле, махсус хәрби операция темасы да читтә калмады. Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, Татарстан Россиянең яңа төбәкләренә булышуын дәвам иттерә.

– Шунысы мөһим: Ватан язмышын хәл иткәндә, Татарстан халыклары ассамблеясы, иҗтимагый һәм яшьләр оешмаларының берсе дә читтә калмый. Мин милли-мәдәни автономияләрнең Казандагы полигонга җылы киемнәр, мич, казаннар илткәнен, милли ризыклар белән сыйлаганын беләм. Җирле милли оешмалар күп кенә районнарда хәйрия акцияләре дә оештырды, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент башлыгы быел Россиядә игълан ителгән Гаилә елының әһәмиятенә дә тукталды. Моны ул Ассамблеяга республика халыкларының гаилә традицияләре, кыйммәтләре белән таныштыру өчен үзе бер мөмкинлек дип бәяләде.

Ассамблеяда миграция мәсьәләсен дә читләтеп уза алмыйлар. «Монда проблемалар күп, сез моны үзегез дә яхшы аңлыйсыз. Әлеге проблемага багышланган утырышлар үткәрүне дәвам иттерергә кирәк», – диде

addnt.ru

ул. Милли-мәдәни автономия җитәкчеләренә исә чит ил студентлары белән очрашулар үткәреп, илнең рухи-әхлакый кыйммәтләрен, федераль һәм республика законнарын аңлатырга кушты.

Конференциядә Татарстан халыклары ассамблеясы башкарма комитеты җитәкчесе Константин Яковлев һәм Татарстан Халыклар дуслыгы йорты директоры Тимур Кадыйров узган елларда башкарылган эш турында хисап тотты. Ахырда исә Ассамблея советының яңа составы, башкарма комитет җитәкчесе һәм рәисе сайланды. Конференциядә катнашучылар Фәрит Мөхәммәтшинның әлеге вазыйфасында калуын бертавыштан хуплады. Башкарма комитет җитәкчесе булып Ренат Вәлиуллин эшләячәк. Моңа кадәр ул Татарстанның Санкт-Петербургтагы һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле булып эшләде.

Сәрия МИФТАХОВА

Уйлап уйна

<Ахыры. Баше 1 нче биттә

Вице-премьер искәрткәнчә, Россиянең барлык төбәкләрендә дә диярлек фиджитал федерацияләр барлыкка килгән. Дөнья күләмендә бу хәрәкәтнең 63 вәкиллеге ачылган. «Бу хәрәкәтне инде туктатып булмый», – диде Дмитрий Чернышенко.

Россиянең спорт министры Олег Матыцин исә үзәкне киләчәккә мирас дип атады.

– Идел буе дәүләт университетының «Киләчәк уеннары» мәйданчыкларының берсе булуына сөенәм. Бу – киләчәгебезгә өлеш кертү. Студентлар спорт белән шөгыльләнү мөмкинлегенә ия. Казан тәҗрибәсен башка югары уку йортларына да тәкъдим итәргә була. Акыл сәләтләре кешенең физик мөмкинлекләре белән тәңгәл килергә тиеш, – диде федераль министр.

Инде янә яңа ачылган үзәккә әйләнеп кайтыйк. Үзәкнең җитәкчесе итеп Руслан Артемьевны билгеләгәннәр. Ул – Идел буе спорт һәм туризм университетының икътисад һәм идарә кафедрасы мөгаллиме.

– Россиядә мондый үзәкләр өчәү. Әмма Казандагысы – иң алдынгысы, иң кәттәсе, – ди ул. – Үзәкнең ишекләре фиджитал юнәлеш белән кызыксынган кешеләр өчен ачык. Әле менә ачылуыбызга бер генә көн, инде шау-гөр килеп уйнаучыларыбыз бар. Кешеләр күп килер дип уйлыйм. Бу үзәкнең киләчәге бар. Минемчә, андый үзәкләр дә республика буенча күп ачылачак әле.

Инде барысын да компьютерга утырткач, болай да кытлык кичергән эшче һөнәрләргә ихтыяҗ тагын да артмасмы? Руслан Артемьев бу җәһәттән борчылмаска куша.

– Моннан куркырга кирәкми. Бөтенесе дә IT тармакка китми бит. Һәркем күңеленә хуш килгәнне сайлаячак, теләгән һөнәрен үзләштерәчәк, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

Рәсми статистика буенча, Россиядә **250 мең**нән артык кеше киберспорт белән шөгыльләнә. Шуларның **40 мең**е – хатын-кызлар. Белгечләр бәяләве буенча, илдә киберспорт белән кызыксынучыларның реаль саны – **15 миллион**нан артык.

* Фиджитал – виртуаль дөнья һәм чынбарлык кушылмасы, берләшүе.

АШ БУЛСЫН!

Яшәеш

Татарстан – эш эзләү өчен ил күләмендә иң отышлы төбәк. Соңгы тикшеренү нәтиҗәләре әнә шуны күрсәткән. Шуңа күрәме, бүген бездә эш эзләүчеләрнең нибары 1 проценты гына республикадан читкә китмәкче. Кемгә нинди эш кирәк? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауга ачыклык кертергә тырышты.

Иң элек шунысын искәртик: Татарстанда эшсезлек дәрәҗәсе иң түбәннәрдән берсе, ул 0,3 процент тәшкил итә. Республиканың Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, 2024–2030 елларда сәнәгать һәм сәүдә тармагына гына да 65 мең белгеч әзерләргә кирәк. Аларның һәр өченчесе диярлек – урта һөнәри белемлеләр, 21 проценты исә – вуз тәмамлаучылар.

Исеме билгеле булган эш табарга ярдәм итүче сайтларның берсе тикшерү үткәргән. Белгечләр илнең кайсы төбәгендә эш эзләү отышлырак икәнен ачыкларга тырышкан. Моның өчен төбәктәге эшсезлек дәрәҗәсе, тәкъдим ителгән вакансияләр, хезмәт хакы белән яшәү минимумының үзара нисбәте кебек хезмәт базарындагы төп күрсәткечләрне исәпкә алганнар. Әнә шулардан чыгып, иң күбе 100 балл җыярга мөмкин.

Озын сүзнең кыскасы, Татарстан, барлыгы 77 балл җыеп, рейтингның иң югары баскычына күтәрелгән. Әйтүләренә караганда, республикада бер вакансиягә уртача 3,3 резюме туры килә. Уртача хезмәт хакы – 59 мең 600 сум. Шул ук вакытта төбәктә эшкә сәләтлеләр өчен яшәү минимумы – 14 мең 317 сум. Тагын бер кызыклы мәгълүмат: Татарстанда эш эзләүчеләрнең 1 проценты гына, эш эзләп, республикадан китәргә теләвен әйткән. Эш эзләүчеләрнең 80 проценты: «Татарстаннан читтә эш тәкъдим итмәгез», – дип кистереп әйткән.

Сан

Рәсми мәгълүматларга караганда, Татарстан оешма-предприятиеләрендә былтыр уртача хезмәт хакы **60** мең сум чамасы тәшкил иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рейтингтагы беренче биш урында Татарстаннан тыш, Ямал-Ненец автономияле округы, Рязань, Свердловск өлкәләре һәм Башкортстан бар. Мәскәү – исемлекнең алтмыш бишенче баскычында.

Түбән Камада яшәүче Ленар Закиров эш эзли.

– Мин белгечлегем буенча инженер-механик, шәһәрдәге шәхси оешмаларның берсендә биш еллап эшлим, – ди егет. – Биредә хезмәт ягыннан үсү мөмкинлеге юк. Шуңа күрә зур предприятиегә урнашасым килә. Анда хезмәт хаклары да яхшырак, билгеле. Резюмелар җибәрдем. Дүрт ай эчендә нибары ике тапкыр эшкә чакырып шалтыраттылар. Тик шартлары туры килмәде. Көтәм.

Татарстан Икътисад министрлыгы хәбәр итүенчә, узган ел азагында республикада 4,3 мең кеше рәсми рәвештә эшсез дип теркәлгән. Алар арасында югары һәм урта белемлеләр, авылда яшәүчеләр, алдагы эшеннән үз теләге белән китүчеләр, яңадан эшкә әйләнеп кайтырга теләүчеләр, инвалидлар һәм пенсиягә чыгу яшенә җитүчеләр күбрәк. Шул ук вакытта, эшсезләр арасында 16–21 яшьлекләр, тәүге тапкыр эш эзләүчеләр, балигъ булмаган бала тәрбияләүчеләр һәм хатын-кызлар саны кимегән.

Фикер

Илдус САФИУЛЛИН, икътисад белгече:
– Аңлашыла ки, эшсезлек дәрәҗәсе түбән булу эш тәкъдим итүчеләр арасында көндәшлек тудыра. Ә эш эзләүчене ничек кызыктыралар? Югары хезмәт хакы белән, әлбәттә. Шуңа күрә Татарстанның югарыда телгә алган рейтингның беренче баскычында урнашуы гаҗәп хәл түгел. Без бүген «демографик упкын» нәтиҗәләрен дә тоябыз. Бигрәк тә, эшче көчләр җитми. Шуңа күрә хезмәт базарында өлкән яшьтәгеләрнең дә кадере артты.

КАЙСЫ ТАРМАКТА КЕМНӘР ҖИТМИ?

✓ Сәнәгать тармагы (слесарь-ремонтлаучы, җиһазларны көйләүче, үлчәп төрүче);
✓ төзелеш тармагы (төзелеш-монтажлау эшләрен башкаручы, диварга бәйле эшләрне башкаручы оста, электромонтажлаучы);
✓ сәүдә тармагы (кассир, сатучы, кибет администраторы).

– Эшнең булганы кадерле, – ди башкаладагы АТПларның берсендә сакчы булып эшләүче Мансур Гарифуллин. – Егерме елдан артык автобус йөртүче булып эшләдем. Бу – бик җаваплы эш. Утырып эшләү сәламәтлеккә дә зыян салмыйча калмады, билгеле. Шуңа күрә лаеклы ялга чыккач, һөнәремне алмаштырып, бирегә үк сакчы булып эшкә урнаштым. Мөмкинлеге булганда, кеше гел хәрәкәттә булырга тиеш дип саныйм. Быел кар көри-көри яшәреп бетәбез бугай. 18–20 мең сум пенсия акчасына яшәү дә бик авыр. Шуңа күрә эш булып торсын.

Хәер, илдә яшәүчеләрнең күпчелеге шул фикердә. Соңгы сораштырудан күренгәнчә, респондентларның 84 проценты, лаеклы ялга чыккач та, эштән туктарга җыенмый. «Зарплата.ру» тикшеренү үзәге хәбәр итүенчә, ил халкының 28 проценты хәле беткәнче хезмәтен ташламаячак. Респондентларның тагын 23 проценты «үзен җәмгыятькә кирәкле итеп тою өчен» эшләвен әйткән. Россиялеләрнең һәр алтынчысы исә тормышын эштән башка күз алдына да китерә алмый. Илдә яшәүчеләрнең нибары 14 проценты гына, пенсиягә чыккач, рәхәтләнеп ял итәргә җыена. Менә шундый хәлләр!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Үз кулыңда

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Авыру реанимациядән чыкты инде. Күз алдына китерәсезме, хәзер Чаллыда да авыруга йөрәк күчереп утырта алалар. Моңа кадәр ул Казандагы төбәкара клиник диагностика үзәгендә (МКДЦ) генә ясала иде. Хәзер моның өчен тагын бер база бар. Элегрәк бавыр, бөер күчереп утыртудагы казанышларыбыз турында сөйләгән булсак, хәзер ышанып әйтә алам: узган ел без йөрәк күчереп утырту буенча да ил төбәкләре арасында алдынгы урынга чыктык. Былтыр без 26 тапкыр (!) йөрәк күчереп утырттык. Бу – бик зур сан, – ди министр.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш кардиологы Зөлфия Ким сүзләренә караганда, республикада үлем-китемгә китергән барлык чирләрнең 46 процентын йөрәк-кан тамырлары авырулары тәшкил итә.

– Узган ел Татарстанда 6410 кешегә миокард инфаркты булган. Йөрәк-кан тамыры үзәкләрендә 19464 кеше дәваланды. 1315 кеше тромбтан котылды, – дип ачыклык кертте баш кардиолог.

Ничек кенә булмасын, сәламәтлек өчен иң беренче чиратта кеше үзе җаваплы. Бу фикерне брифинг дәвамында Марсель Миңнуллин да кат-кат әйтте.

– Кеше үзе дә сәламәтлегенә игътибарлырак булсын иде. Юкса кайберәүләрне диспансеризация уз инде дип үгетләргә туры килә. Ә бит бу иң беренче чиратта аның саулыгы, аның гомере өчен кирәк. Сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга тиешле 40–65 яшьлек кешеләр арасында еллар буе табибка күренмәүчеләр бар. Үзен яхшы хис иткәч, бар да тәртиптә дип уйлый алар. Ә бит кандагы холестерин күләме, артык авырлык, тәндәге, организмдагы үзгәрешләрне һәрчак контрольдә тотарга кирәк. Алар үзен сиздергәндә инде соң булырга мөмкин, – ди министр.

«Татар-информ»

Министрга 3 сорау

1. Казанда яңа балалар хастаханәсе кайчан төзеләчәк?
– Казандагы беренче балалар хастаханәсенең яңа бинасы быел төзелә башлар дип өметләнәбез. Биредә, ДРКБ белән беррәттән, авыр хәлдәге балаларга ярдәм итәчәкләр. Хәзерге вакытта яңа үзәкнең проекты эшләнә.

2. Татарстанда тагын бер онкология диспансеры төзеләчәкме?
– Бүген башкаладагы онкология диспансеры көчәйтелгән режимда эшли. Әлегә табиблар җилкәсенә төшкән йөкне авырулар ташкынын башка оешмаларга да юнәлтү хисабына киметеп карарга җыенабыз. Республика онкодиспансеры эшен камилләштерүне күздә тоткан берничә проект бар. Ул сырхауханәгә дә, химия терапиясе бүлекләренә дә кагыла. Бүген бездә 7 амбулатор онкология ярдәме үзәге эшләп килә. Анда көндезге стационарда химия терапиясе уздыралар. Авырулар шунда озатыла башласа, республика онкология диспансерының химия терапиясе бүлегендәге халык агымы да бераз кимер иде.

3. Укучы соравы: «Ел саен диспансеризация узам. Әмма мине бер тапкыр да дерматологка җибәргәннәре булмады. Ни өчен шулай икән? Табиб дерматологка ниндидер шик туган очракта гына җибәрергә тиешме әллә?»
– Әйе, шик туган очракта терапевт кешене дерматологка җибәрә. Аннары ул алга таба онкодиспансерга юлларга мөмкин. Әмма бу очракта кешенең үзенең дә аң булуы кирәк. Әгәр тәндә сәер таплар пәйда булса, теге яки бу миң шик уятса, алар зурайса яки күбәйсә, бу хакта түкми-чәчми табибка сөйләргә кирәк. Әгәр ул зары була торып та дәшми икән, кешенең үзенә дә, табибка да кыенрак булачак.

Динә ГЫЙЛӘҖИЕВА

23 февраль – Ватанны саклаучылар көне

КУРКАК БУЛМАСАҢ, ТИМӘСЛӘР

Ватанны саклаучылар көне дип үзгәртелсә дә, без күбесенчә бу көнне барыбер армия белән бәйләргә яратабыз. Без үскәндә, Совет Армиясе көне иде ул. Гадәттә, хезмәт иткән егетләребезне, улларыбызны, әтиләребезне котладык. Хәзер дә шулайрак. Әмма «армия» дигән сүз булмагач, ир-атларның барысын да котлыйбыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хәзер хезмәт итү срогы бер ел гына булгач, «ай күрде, кояш алды» кебек. Китеп кенә бара егет, кайтып та җитә. Хәер, читләргә генә шулайдыр инде ул. Хезмәт иткән кешегә дә, түземсезләнеп көткәненә дә һәр минуты озак кебек тоеладыр. Элек, ике яки өч ел хезмәт иткәндә, армиядәге хәлләр турында көлеп тә, елап та сөйлиләр иде. Күбрәк «бабай»лар, «карт»лар тарафыннан эшләнгән маҗаралар турында искә алалар иде.

Редакциягә йомыш белән килеп чыккан Наил абый Кәлимуллин белән дә сүзебез, ничектер, шушы темага кереп китте. Бәйрәм көннәре якынлашканга искә алганбыздыр, күрәсең.

«Дед»лар китте

– Мин армиягә ветеринария техникумын тәмамлагач алындым. Ракета гаскәрләрендә пешекче булып хезмәт иттем. Ике атна карантинда булгач, частьларга тараттылар. Тезеп бастырдылар. Фамилияне әйткәч, бар да миңа әйләнеп карады, әйтерсең лә зоопарктагы маймыл, татар күргәннәре юк, ахры, дип уйладым. Чыннан да шулай булып чыкты. Татарлардан мин берүзем. Күбесе белорус, әрмән егетләре. Икенче көнне яныма кичерәк буйлы бер солдат килде. Дембель икән. «Зинһар, миңа сәгатеңне бир әле, җәл булмаса, өйгә кайтканда тагар идем. Китүчеләр бездән дә шулай сорадылар», – ди. Мин аңа сәгатемне генә түгел, «Харьков» кырынгычын, булган акчамны да тоттырдым. «Бик зур рәхмәт инде», – дип кулымны кысты. «Барыбер талап алырлар иде, ә бу яхшы итеп сорады, рәхмәтен дә әйтте», – дип күңелемне юаттым.

«Старик»лар калды

«Дед»лар киткәч, «старик»лар хуҗа булып калдылар. Үзләрен бик иркен тотып, яманрак кылана башлады болар. Бервакыт шулай бәдрәфкә кереп барам. Берничәсе тәмәке тартып сөйләшеп тора. Озын, чандыр гына гәүдәле, Гончаров фамилияле белорус егете: «Комачаулап йөрмә монда», – дип мине куа башлады. «Мин сезгә комачауламыйм, хаҗәтемне үтим дә китәм», – дигәнне яратмады, төрткәли башлады. Минем дә кан кызып китте. Бәргәли башладым. Көчкә аерып алдылар. «Темный» ясамасыннар дип, берничә көн куркып йөргән идем. Тиюче булмады. Шунда аңладым: армиядә мескен булып йөрү куркаклар өлешенә тия икән.

Беренче тапкырдан ук бик алай батыраеп та китә алмас идем. Сәбәбе бар. Аннан алдарак бер майор, яңа килгәннәрне берәм-берәм чакырып, сөйләшү үткәргән иде. «Акчаларыңны, әйберләреңне алмадылармы? Кыерсытмыйлармы? Гәүдәң бар, каршы тор, курыкма», – диде. Үзем чыгарып бирдем дип әйтә алмадым инде. «Төрмәгә ябып куярлар бит», – дип кенә шикләнүемне белдердем. «Син яшь, карт солдатлар үзләренә кул күтәргәнне әйтергә хурланачак», – диде.

«Андый юлга бармадым»

Үземә эләккәләсә дә, яшь солдатларны бер тапкыр да рәнҗетмәдем. Гөнаһыннан курыктым, кешедән көлү фигылемә дә ярамый.

Беркөнне шулай булышырга дип, яшь солдат бирделәр. Шәһәр малае бу. Бәрәңге дә әрчи белми, идән дә юа алмый. Җәлләдем инде. Җиңнәрне сызгандым да үзем юа башладым. Кухняда пычрак булса, миңа да эләгә бит. Шулай тырыша-тырыша юып ятканда, штаб башлыгы килеп керде. «Син идән юган куллырың белән безгә ризык әзерлисеңме? Бу ни хәл бу?» – дип әрләп атты. Мин, каушаган кыяфәт чыгарып: «Нарядка яшь солдат бирделәр. Өлгерә алмый. Булышмакчы гына идем. Гафу итегез», – дип, гаепне үз өстемә алдым. «Алайса икенчесен бирербез, үзең юма», – дип елмаеп чыгып китте. Яшь солдатка да берни булмады.

Ничек кенә булмасын, армия елларын вакыт узган саен ешрак искә алам, сагынам мин. Ул безне яшәргә, нык булырга, дөньяны танып-белергә өйрәтте. Вактөяк күңелсезлекләр булса да, төрле милләт егетләре белән аралашып, бер-беребезнең гореф-гадәтләрен белергә теләү, сорашулар искә төшә. Аларның фотоларын карыйм. Ничек яшиләр икән? Их, барысы белән дә очрашасы, аралашасы иде. Кызганыч, хәзер без бер дәүләттә түгел шул,чикләр аера…

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Симет» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Саба районы) **Зәйнетдинов** Шамил Җәмил улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Филармония джаз-оркестры сәхнәгә куючы режиссеры **Әхмәтов** Рөстәм Ринат улына **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Лаеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Коробова** Елена Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«БУА ИКМӘК ЗАВОДЫ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте лаборанты **Багитова** Лилия Касыйм кызына, «Күмәч-кондитер комбинаты» акционер җәмгыятенең производство белән идарә итү системаларын автоматлаштыру бүлеге башлыгы **Вяткин** Павел Славовичка, «Күмәч-кондитер комбинаты» акционер җәмгыятенең икмәк-күмәч цехы азык-төлек продукциясе производствосында җиһазларны көйләүче **Никитина** Ирина Юрьевнага; «Алабуга ит консервасы комбинаты» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: баш инженер **Вахитов** Руслан Наил улына, колбаса цехы эшчесе **Закирова** Татьяна Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Шытсу» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 1 бригадасы бригадиры (Татарстан Республикасының Саба районы) **Салихов** Илгиз Хатип улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Малышев исемендәге Столбище урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Шмелёва** Наталья Геннадьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация:

– о структуре и объеме затрат на производство и реализацию товаров (работ, услуг) ООО «Альтернативная энергосбытовая компания»;

– об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Авыл җаны

Атлы нәсел

Әлмәт

Әлмәт районының Бишмунча авылында яшәүче Резеда һәм Рүзил Мөхәммәдиевләр авылның бар тәмен һәм ямен тоеп яши. Матур гаиләдә өч бала тәрбияләп үстерәләр. Һәм иң кызыгы: әтиләре өч балага өч ат бүләк иткән.

– Иремә ат җене кагылган дип әйтсәң дә була. Элек аның әтисе белән әнисе колхозда эшләгән. Атларны бик яратсалар да, хуҗалыкларында асрарга мөмкинлек булмаган. Ә Рүзил гомер буе атлар асрау, аларны тәрбияләү турында хыялланган. Шуңа күрә ирем хыялын менә хәзер тормышка ашырып яши, – дип елмайды Резеда.

Хуҗалыкларында ат тоту теләге исә, балалары тугач, тагын да ныгыган.

– Олы кызыбыз да атларны бик ярата. Үз-үзен белә башлаганнан бирле әтисеннән ат сорый иде. Әтисе исә кызыбызга 10 яше тулгач, ат бүләк итәргә вәгъдә бирде. Бер балага ат кадәрле ат аласы булгач, башкалары нишләр икән соң, дип уйлаштык-киңәштек тә, Рүзилә белән Ильяска да колын бүләк итәргә булдык, – ди әниләре.

Менә шулай итеп, балаларның да, әти-әниләрнең дә бар мәшәкате, игътибары колыннарга юнәлә. Ашату, карау һәм, әлбәттә инде, ярату. Инде хәзер атлар үсеп җитеп, тагын бер колынга баеганнар. Ашату, эчертү кебек мәшәкатьләр – әти-әниләр җилкәсендә. Балалар да ярдәм итә. Ә төпчекләре Ильяс атларны Сабан туена матур итеп җигеп чыгу хыялы белән дә яши әле.

– Шунысы гаҗәп: һәр баланың аты холкы белән нәкъ менә үзләренә охшаган, – дип елмая Резеда. – Әйтик, олы кызның Першик кушаматлы аты үзе шикелле тыныч, сабыр, ачык. Уртанчы кызыбызның Снежинкасы горур, башбирмәс, үзен рәнҗетергә юл куймый, усал, әмма гадел. Башкалар янында дусларын да кыерсыттырмый. Төпчек улыбызның Йолдызы да гел үзе төсле: йомшак, ачык, мөлаем, иркә һәм тыйнак.

Ир белән хатын 15 ел эчендә бер-берсен ярты сүздән, караштан ук аңларга өйрәнеп беткән инде. Шуңа күрә иренең ат яратуы балаларга гына түгел, хатынына да күчкән.

– Кешеләр бездән еш кына: «Атларны кайчан чаласыз инде?» – дип кызыксына. Тик без аларны аның өчен тотмыйбыз. Ат итен гомумән ашамыйбыз. Без аларны ниндидер файда, табыш өчен алмадык. Атлар бары тик күңел тынычлыгы гына китерә. Без алар янында ял итәбез, күңелебезгә тынычлык табабыз. Атлар безнең гаилә әгъзасы кебек якын, – ди алар.

Атлардан тыш, яшь гаилә таналар да асрый. Билгеле, терлек асрагач, мәшәкате дә җитәрлек. Эштән кайткач, аларны карыйсы, җәен азыгын хәстәрлиселәре бар.

– Җәй буе үзебез чабып алып, печән әзерлибез. Аның да үзенә күрә бер рәхәте бар. Эштән кайтуга болыннан яшел печән чабып алып кайтабыз. Җитми башласа, язын сатып та алгалыйбыз. Авылдашлар арасында: «Нигә интегәсез, җәегез печән әзерләп уза бит», – дип әйтүчеләр дә бар. Иремнең андыйларга җавабы бер: «Бу – минем күңелем кушкан эш, сез миңа игътибар итмәгез», – ди ул.

Балаларын да хезмәт белән үстерергә тырышалар. Инде буй җиткезгән кызлары да кул арасына керә, төпчекләре дә апаларыннан калышмый. Һәркайсының үзенең җаваплы эше бар.

– Өч балабыз да мәктәптә укый. Шөкер, тырышалар, булдыралар. Кызларыбыз күрше авылга йөреп белем ала, төпчегебез авылда икенче сыйныфта укый. Үзем дә мәктәптә эшлим. Кызганыч, авылыбызда башлангыч мәктәп кенә бар. Барлык классларны да шушында укысалар, бик рәхәт булыр иде дә бит, – дип, күңелен тырнап торган мәсьәләне дә күтәрде әни кеше.

Менә шулай, бар булганына шөкер итеп, булмаганын бергә булдырып, күңел кушканча яшиләр Мөхәммәдиевләр.

– Авылның тынычлыгын һәм иркенлеген берни белән дә чагыштырып булмый. Мин тумышым белән Бөгелмә районының Карабаш авылыннан. Ул – шәһәр тибындагы бистә. Әти-әнием дә фатирда яшәде. Ә монда үзебез йорт җиткезеп, үз ихатабыз белән яшибез. Шуңа күрә хәзер әниләргә кунакка баргач та, тизрәк үзебезгә кайтасы килә, – ди Резеда.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«ПАПА», «МАМА»ЛЫ ЗАМАН

21 ФЕВРАЛЬ – ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ УҢАЕННАН УЙЛАНУЛАР

Әти-әнисе татар була торып та, баласы аларга «папа», «мама» дип эндәшкән куркыныч заманда яшибез... Эш милли үзаң дәрәҗәсе түбәнлегендә генәме икән? Туган телебезнең киләчәген якты итү өчен хәзер нишли алабыз? Уйга салырга тиешле бәйрәм уңаеннан без әлеге сорауларга җавап табарга тырыштык.

Туган тел турында сөйләшү – иң авырткан җиребез. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрә **Илсөяр Иксанова** сүзләре бу.

– Әйе, Татарстанда туган телне саклау өчен дәүләт тә, иҗтимагый оешмалар да, хәтта аерым энтузиастлар да төрле юллар, формалар кулланып карый. Ләкин барыбер дә мәгариф системасына барып төртеләбез. Кызганыч, без тәэсир итә торган мәсьәлә булып чыкмады ул. Нинди генә чаралар уздырсаң да, мәктәптә туган тел дәресләре җитәрлек дәрәҗәдә укытылмаганда, проблема хәл ителмәячәк, – ди ул.

Кешедә милли үзаң булырга тиеш. Ләкин бу «тиеш» белән генә булмый. Илсөяр ханым телнең куллану даирәсен киңәйтергә кирәклеген әйтте.

– Кеше шулай яратылган: ул рациональ якны да карый. Әгәр теге яисә бу тел аңа кирәк икән, ул аны өйрәнә. Моңа мисал – инглиз теле, – ди ул. – Гомумән, бу – глобаль проблема. Ләкин алай дип кенә кул кушырып утырырга ярамый. Һәркем үз урынында, үзе булдыра алганча һәм намусы кушканча туган телен сакларга тиеш. Мин татар кешесенең балаларының «папа», «мама» дигәненә риза булып утырганына шаккатам... Наданлык, үз-үзеңне хөрмәт итмәү инде бу...

Татарстан китап нәшриятының балалар редакциясе мөдире, җәмәгать активисты **Айсылу Галиева** да, тел саклансын өчен, аңа ихтыяҗ булу кирәк, ди. Ә бездә ул...

– Туган тел көне – ясалмарак, уйлап табылган көн инде ул. Елга бер генә туган тел көне була алмый бит, – диде ул бәйрәм җәһәтеннән. – Республикада татар теленә мөнәсәбәт «өчле»дән түбән. Халыкның бик аз өлеше генә катнаша торган чаралар: олимпиадалар, конкурслар, форумнар гына тел саклауга ярдәм итми. Тел саклансын өчен, аңа ихтыяҗ булу кирәк. Ни өчен рус телен өйрәнәбез? Чөнки БДИ бирәсе бар. Чөнки яхшы эштә эшләү өчен дәүләт телен белергә кирәк. Чөнки син ул телне белмәсәң, кирәгеңне аңлата алмыйсың.

Бүген һәм хәзер туган телебез өчен нәрсә эшли алабыз?

– Телне саклау өчен, беренчедән, республикада ике дәүләт телен дә кулланучы муниципаль, дәүләт, бюджет, сәүдә, хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләргә күбрәк хезмәт хакы түләргә, татар (районына карап, чуаш, удмурт) телләрендәге язуларны (элмә такталар, юл күрсәткечләре, җәмәгать урыннарындагы белдерүләр һ.б.) куллану, мәктәптәге БРИны кире кайтару, муниципаль җирлекләргә бәйле булмаган, татар телендә дә белем бирә торган полилингваль мәктәпләрне, бакчаларда чынлап та татар телле төркемнәрне эшләтү, банк, дәүләт хезмәтләрен башка телләрдә дә алу мөмкинлеген булдыру – гомумән, татар теле белән дә бер проблемасыз көн итү мөмкинлеген булдырырга кирәк, – ди Айсылу Галиева.

Фәнни яктан караганда, телебез ни хәлдә? Бу сорауны Татарстан Фәннәр академиясе Гамәли семиотика институтының өлкән фәнни хезмәткәре **Марат Шәехов**ка бирдек.

– Фәнни яктан караганда туган телебезнең хәле мактанырлык түгел шул. Диссертацияләрне татар телендә яклауны кире кайтармыйча бу хәл үзгәрер дип уйламыйм. Ким дигәндә, яшь галимнәрнең милли үзаңын саклау һәм үстерү өчен тырышырга, аларга туган телләрендә аралашу һәм фикерләрен уртаклашу аланнары булдырырга кирәк дип уйлыйм. Хәзерге вакытта популяр булган юнәлешләргә, мәсәлән, ясалма интеллект кебек актуаль темаларга игътибарны җәлеп итеп, бу темаларга татарча фәнни-популяр мәкаләләр язудан файда булыр дип өметләнәм, – диде ул.

Туган телгә игътибар җәһәтеннән үзебезне генә түгел, читтә яшәүче милләттәшләрне дә онытып бетермәскә кирәк дигән фикердә ул.

– Шөкер, Татарстанда татар теленә игътибар саклана, һәм без моның белән горурланабыз, моның белән мактанып та алырга яратабыз. Ләкин карашыбызны бераз еракка ташлап, башка төбәкләрне һәм илләрне дә күз уңына кертә башласак, яхшы булыр иде, – диде Марат Шәехов.

Киләчәккә карап фикер йөртәбез икән, яшьләргә сүз бирик. Татар теле һәм әдәбиятыннан Халыкара олимпиада җиңүчесе **Ихтыяр Кыямов** телне сакларга алынганбыз икән, төп игътибарыбызны яшьләргә юнәлтергә кирәк дип саный.

– Әйе, күп кенә балалар берәр чарада, бәйгедә катнашса, сәхнәгә чыгып матур итеп шигырь сөйли, яисә татарча җыр башкара ала. Ләкин бит телнең куллану даирәсе сәхнә белән генә чикләнми, ул көндәлектә булырга тиеш. Туган телебез фәкать сәхнәгә чыкканда гына кулланыла торган коралга әйләнмәсен иде, – ди ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ихтыяр фикеренчә, телгә карата хөрмәт, игътибар кими ала, ләкин телнең әһәмияте җуела алмый.

– Билгеле, 1990 нчы еллар белән чагыштырганда, телебезгә карата игътибар кимеде кебек. Бер яктан карасак, Татарстан Рәисе каршындагы Телләр комиссиясе эшчәнлеге телебезнең, мәдәниятебезнең үсешенә сизелерлек уңай йогынты ясый. Төрле-төрле чаралар һәрдаим үткәрелеп тора. Мин моны мәктәптә укыган чагымда аеруча сизә идем. Ләкин шул ук вакытта яшьләр арасында туган телләрендә сөйләшү кими бара. Әйтик, мин бик сирәк яшьтәшләрем белән татарча сөйләшә алам, һәм бу – бик кызганыч хәл.

И туган тел, и матур тел – оялмый сөйләшә бел!..

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Соклану

ЕЛАТА ТОРГАН РӘССАМ

Гүзәлнең картиналарына очраклы рәвештә генә тап булдым. Милли рух белән сугарылган иҗат җимешләре игътибарны җәлеп итеп кенә калмады, болай гына аңлатып булмый торган хисләр уятты. Баксаң, безнең милли традицияләрне картиналарында яшәтүче Самара кызы Гүзәл Хәйбулловага мондый кайтавазлар еш килә икән.

Беренче адымнар

Самарада туып-үскән 23 яшьлек Гүзәл кечкенә чакта уенчыклардан бигрәк, пумала-буяуны өстен күргән. Самараның «Яктылык» татар мәктәбендә белем алган чакта сәнгать мәктәбендә дә укыган.

– Рәсем сәнгатенең төрле юнәлешләрендә эшләп карадым. Гарәп каллиграфиясе белән өй, офис диварларын бизәдем, шундый стильдә картиналар ясадым. Хәзер инде иҗатымны халкыма багышларга булдым, – ди әңгәмәдәшебез.

Гүзәл балачактан үзенең башкаларга охшамаганлыгын яхшы аңлый. Татар мәктәбендә укый башлаганчы, татар мохитен бары әти-әнисе янында гына күрә ул.

– Башкаларга охшамавымнан кимсенмәдем, киресенчә, моны һәрвакыт үзенчәлегем итеп кабул иттем. Архитектура-төзелеш академиясендә укыган вакытта үз миссиям турында уйлана башладым. Аллаһы Тәгалә шундый сәләт биргән икән, мин иҗатым аша ниндидер мәгънәләр җиткерә, үз мәдәниятемне, тарихымны картиналарымда саклый, алар аша популярлаштыра алам бит – шуны аңладым. Милли тема рәсем сәнгатендә бик сирәк очрый. Шуңа да бу темага алынуым сөрелмәгән кырга кергән кебек булды, – ди Гүзәл.

Картиналары белән башкаларны илһамландырасы килә аның. «Саклагыз, кадерләгез, бу бик кирәк сезгә!» – дип түгел, ә традицияләрнең мәхәббәт теле булуын аңлатып.

> Кешеләр өйләрендә милли тематиканың нигә кирәген аңлап бетермиләр иде. Иң беренче чиратта мин төрле каналлар аша шуны аңлатырга тырыштым. Элек татар йортларында милли бизәкләр зур урын алып торган, ә хәзер алар бер-берсенә охшап бетте. Милли стильдә ясалган картина элеп куеп кына да өйгә үзенчәлек, ямь өстәп була бит.

Моңлы сурәтләр

Пумала-буяуга алынганчы, картинаның нинди буласын күз алдына китерергә кирәк. Кайчак аның идеясен уйлап табуга вакыт күбрәк кирәк була икән. Аеруча тулы бер серия иҗат иткән чакта.

– Картиналар бер-берсенә «ялгансын», тулы бер сюжет килеп чыксын өчен, озаклап уйланам. Шуннан соң инде ясарга тотынам. Идеядән алып әзер картина арасында, гадәттә, берике атна вакыт була. Ә иң күп вакыт шушы картиналарны дөньяга танытуга, төрле социаль челтәрләргә куюга китә, – ди Гүзәл.

Гел зур-зур картиналар, катлаулы серияләр ясау белән генә шөгыльләнми ул. Кулайрак бәягә бераз гадирәк картиналар да ясарга кирәк дип саный. Шулай булмаганда, сәнгатьне киң массага тарату авыррак...

– Иң кыйммәтле картинамның бәясе – 53 мең сум. Ул «Чәй куегыз!» дип атала. Аның идеясе интернетта шактый таралган бер кызыклы видеоны карагач туды. Бер казах гаиләсендә кыз бала әтисе белән язышa икән. Тик ул нәрсә генә язса да, әтисе аңа: «Чәй куегыз!» – дип җавап кайтара. Күпләр бу видеода үз әтиләрен, үз гаиләләрен күргән дип уйлыйм. Гомумән, төрки халыкларның тормышында чәй аерым урын алып тора. «Чәй куегыз!» картинасында мин нәкъ менә шуны һәм безнең халыкның кунакчыллыгын күрсәтергә теләдем, – дип сөйләде безгә рәссам.

Гүзәлнең иң катлаулы һәм күпләрне елаткан картинасы «Чыгарсыңмы каршы алырга?» дип атала. Шулай ук кечкенә булса да тарихлы картина ул.

– Байбулат Батулланың «Ядәч! Истә!» фильмы илһамландырды. Анда яңгыраган көйләргә, аеруча Илһам Шакировның «Сарман вальсы»на тагын бер кат гашыйк булып кайттым. Өйгә кайтуга, күз алдына булачак картинам килеп басты. Һәм мин татар чәчкәләре арасында татар читеге киеп басып, сөйгән ярын каршы алучы яшь кызны сурәтләдем. Яшьлек, мәхәббәт, тугрылык – «Сарман вальсы»ндагы әлеге төшенчәләрне картинамның нигезе итеп алдым. Һәм, beләсеңме, аны сатып алган ханым, кулына алуга, хәтта елап җибәргән. Гомумән, әлеге картинага кайтавазлар бик күп килде. Күпләргә ул яшьлеген искә төшерде, кемнедер балачагына алып кайтты. Картиналарымда визуаль һәм мәгънәви якны берләштереп, кешеләрдә мондый хисләр уята алуыма әйтеп бетергесез шат мин, – ди Гүзәл.

Әлеге ике картина да «Ярату» сериясенә карый. Ул сериядә Гүзәл төрки халыкларның традицияләр аша мәхәббәт аңлатуын сурәтли.

– Соңгы арада минем иҗатыма битараф булмаучылар шактый артты. «Ярату» сериясенә караган картиналарымны бик күп сорыйлар. Мин аларны Казанда да күрсәтергә телим. Гомумән, минем Татарстан башкаласына күченәсем килә. Хәзерге вакытта мин моның өчен кулымнан килгәнне эшлим. Анда мине тагын да зуррак мөмкинлекләр, идеяләр көтә кебек...

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 220

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+

ӘФЛИСУН

1 стакан әфлисун согы сыгу өчен өч әфлисун җитә. Ул сәламәтлек өчен бик файдалы.

Аны даими рәвештә кулланганда, организмдагы шлаклардан арынырга ярдәм итә һәм бөердә ташлар барлыкка килүдән саклый.

Әфлисун согы шулай ук органик кислоталар, флавоноидлар, бик күп минераллар чыганагы булып тора. Составында калий һәм магний булу инфаркт һәм инсультны кисәтә.

Кан тамырларын ныгытучы P витамины белән аскорбин кислотасы кан савыдан саклый. Бу җимешнең цинк һәм йод, фтор һәм кобальт, фосфор һәм хлор, натрий һәм кальцийга бай булуын да истән чыгармаска кирәк. Ә составындагы тимер – анемияне булдырмау һәм дәвалау өчен бик яхшы чара.

Файдасы күп булса да, түбәндәгеләрне истән чыгармаска кирәк.

Аллергияле кешеләргә, өч яшькә кадәрге балаларга, шикәр диабетлы кешеләргә, ашкайнату системасы авырулары булганнарга әфлисун согын саклык белән эчәргә киңәш ителә. Әфлисун теш эмалена зыян китерергә мөмкин. Шуңа да аны ашаганнан соң, йә согын эчкәч, тешләрне чистартырга, авызны су белән чайкатырга кирәк.

Файдалы киңәшләр

ЭРЕМЧЕК СУЫ

Аның файдасы әйтеп бетергесез. Анда сөт шикәре, минераль тозлар, тиз үзләштерелә торган аксым бар.

– Сөт шикәре эремчек суына эч йомшарта торган үзлек бирә. Шуңа күрә эч кипкәндә эремчек суы эчәргә киңәш ителә.

– Ул сидек кудырырга сәләтле, шешенүне бетерә.

– Моннан тыш эремчек суы ашказанындагы черүче флораны тышка куа, яшь, файдалы флора үстерергә булыша. Эремчек суын ач карынга иртән эчәргә киңәш ителә. Аны көнгә бер стакан эчү җитә.

– Ябыгу өчен 1,5–2 литр эремчек суы кирәк. Аны көн дәвамында дүрт өлешкә бүлеп, шикәрсез чәй һәм су белән чиратлаштырып эчәргә киңәш ителә. Бу диетаны җиде көнгә бер тапкыр бер ай дәвамында кулланырга була. Ул организмны чистарта, ашказаны эшчәнлеген, матдәләр алмашын яхшырта. Эремчек суын бер атна дәвамында кичке аш урынына кулланып та артык авырлыктан котылырга була.

– Целлюлиттан да арынырга ярдәм итә. Моның өчен көненә бер стакан эремчек суы эчәргә кирәк.

– Моннан тыш, ул чәч һәм тырнакны да ныгыта.

ЗӘҢГӘР МӘТРҮШКӘ

Зәңгәр мәтрүшкәнең файдасы бик зур. Ул табигый антибиотик булып санала.

Составында корвалол, аскорбин кислотасы, дуплау матдәләре, эфир майлары күп. Ашказаны согы бүленеп чыгуны арттыра, тән температурасын төшерә, ютәлләгәндә ярдәм итә, артык холестеринны куа. Ант шулай ук нерв авыруларыннан да, кан басымы югары булганда, атеросклероздан һәм башка очракларда да кулланалар. Хуш исле үсемлекне баш авыртканда, йокысызлыктан җәфаланганда да эчәләр, тәнәтмәсе белән баш юалар. Теш сызлаганда чәйниләр. Элекке заманнарда мәтрүшкәне буыннар сызлаганда, тешләрне таштан чистарту өчен кулланганнар. Мәтрүшкәнең эфир мае кайбер мазьлар составына керә. Моннан тыш, аны сабын, иннек, исемайга хуш ис бирү өчен косметикада да файдаланалар.

СУНЫ НИЧЕК ЭЧӘСЕ?

Суны дөрес эчмәү организмга зыян салырга мөмкин. Кичен су эчәргә мөмкин, әмма аны дөрес эчәргә кирәк.

Табиб-гастроэнтеролог Наталья Слюняева «МедикФорум» хәбәрчесе белән әңгәмәсендә шулай дигән.

– Кичке сәгатьләрдә суны күп эчкән очракта организмнан токсиннар чыгарыла, ашказаны-эчәкләр яхшырак эшли башлый. Ләкин шешенүгә, тәнлә бәдрәфкә еш йөрүгә, йокысызлыкка китерергә мөмкин, – дигән белгеч. Бөерләрә авырлык килмәсен өчен, соңгы стакан суны йокларга 1,5–2 сәгать кала эчеп җибәрү әйбәт. Ә менә йоклар алыннан кәмер һәм кофеинлы эчемлекләр файдага түгел. Алар урынына майсыз сөт эчемлекләре, үләнле (ромашкалы яки бөтнекле) чәй эчү хәерле.

«Суны күп эчү тәнлә бәдрәф юлын таптауга китерергә мөмкин. Бу исә начар йоклау, йокы туймау белән яный», – дип билгеләп үткән табиб.

Гөлләргә салкын кирәк

Орхидея, декабрист, миләүшә гөлләре күптән чәчәк атмаса, аларны 15 минутка +8...+10 градуслы салкынча урынга куеп алырга кирәк. Моны айга бер-ике тапкыр кабатлап алырга мөмкин. Әмма әлеге ысул яран гөл өчен кулланылмый.



Нияз Бишбалта

ҖАВАПЛАР

Горизонталь буенча: бөтнек, укә, тап, сөт, ата, чыпчык, әнт, ал, көл, чыдамлык, әр, мәсәл, марка, мәсләк. **Вертикаль буенча:** әтнә, чүлмәк, таңа, тупса, дала, балтач, маймыл, чиләк, сыер, әр, кисмәк, кар, карапама.

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Фәрит ХӘМИДУЛЛИН.**

Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ

№ 1–2
21 февраль, 2024 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР
Эремчек суы. Ташларга ашыкмагыз
> 3

ЙӨРӘК УНҖИДЕДӘ
Хәния әбигә 95 яшь тулды
> 4

КҮҢЕЛ ТУЛЫ МОҢ
Гармунчыга сүз әйтмәгез!
> 4

Пар канатлар

АЛТЫН ТУЙ

Автор фотосы

Апас

Апаста яшәүче Зина һәм Расыйх Латыйповлар бүгенге тормышларына шөкер итеп яшиләр. 50 ел гомерне елга агышына тиңләүләре дә юкка гына түгел.

– Ярты гасыр вакыт сизелми дә узып киткән. Мин аны су агышына тиңлим. Чөнки суның да дулкынлы, тынып, шаулап аккан, ярларына сыймаган чагы була. Гаиләдә дә шул ук. Тормышта да төрле вакытлар була. Сабыр итә белгән генә тигез, бәхетле картлыгына җитә, – ди алар.

Апас егете Расыйх кечкенәдән тынгысызлыгы, чаялыгы белән аерылып тора. Төп хезмәтеннән тыш, җәмәгать эшләрендә катнаша, мәдәни тормышның үзәгендә кайный. Район мәдәнияте йортында күрсәтелгән «Күрше кызы» спектаклендә комбайнчы ярдәмчесе ролен уйнаган егетне тамашачылар арасындагы Зина күреп ошата.

– Зина «Госстрах» оешмасында эшли иде. Мин район башкарма комитетынннан йомыш белән аларга кердем. Хезмәттәшләре, елмаеп: «Менә артист егет», – дип куйдылар. Зина минем белән кызыксынган булган икән. Оялудан бит очлары кызарып киткән кызга мин дә игътибар иттем. Аннан соң да эш буенча берничә тапкыр очраштык һәм дусլашып киттек, – ди Расыйх абый.

Зина апа озак еллар икътисадчы булып эшли. Расыйх абый җитәкче урыннарны били. Район кулланучылар җәмгыяте җитәкчесе, партия секретаре, икмәк комбинаты җитәкчесе булып эшли.

– Өйдә ышанычлы тыл булмаса, тыныч күңел белән эшләп булмас иде. Өйдәге тормышны Зина алып барды, улыбызны тәрбияләү дә аңа йөкләнгән иде. Ул тормыш имтиханнарын «бик яхшы» билгесенә тапшырып, бүген кадерле әни, сөекле дәү әни булып яши, – ди Расыйх абый.

Зина апа ачык йөзле, уңган-булган, үзенә дә, башкаларга да бик таләпчән. Гаилә учагын сүндермичә, алтын туйга җитү өчен сер бирмәү, сабырлык, әйтеләсе сүзләрне эчкә йота белү дә кирәк дип саный.

– Өйдә ни генә булса да, капкадан елмаеп чыктык. Ачысын да, төчесен дә уздыра белдек. Ачу килгәндә, артык сүз әйтмәс өчен, тизрәк эшкә тотындым. Башым аска иелгән булса да, кояш нурлары җанымны җылытты. Гомернең көзләренә парлап атлау бәхетен без ялып алдык, – ди Зина апа.

Уллары Радик, киленнәре Гөлнара – аларның төп терәге. Оныклары Аделина медицина университетын тәмамлап, бүген ординатурада укый. Ростәмнәре һөнәр үзләштереп, көзен армия сафларына киткән. Дәү әти һәм дәү әнисенә солдат хезмәтеннән сәламнәрен юллап, хәер-догаларын алып тора.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

Оста куллар

Җырлый-җырлый бәйлиләр

Чирмешән

Район үзәк китапханәсенә йөрүче хатын-кызлар яңа эшкә керештеләр – җырлый-җырлый, ыргак ярдәмендә мунчала үрә башладылар.

– Бу түгәрәк инде биш ел эшли, – ди «Җитез куллар» түгәрәге җитәкчесе Әлфинә Батыршина. – Атнага бер тапкыр җыелабыз. Бергәләшеп нинди генә кул эшләре башкармадык. Ярдәмчебез, укытучыбыз – интернет. Бергәләп киңәшәбез дә видеолар карый-карый өйрәнәбез. Флера апа Минхәерованың фантазиясе зур, еш кына ул үзеннән дә яңалык кертеп җибәрә.

Түгәрәктә заманында төрле тармакларда эшләгән, төрле һөнәр ияләре шөгыльләнә. Алар шунда серләшеп тә ала, дөнья хәлләре турында да сөйләшә. Куллары эшли, төрле әйтемнәр дә әйтәләр, җырлыйлар, табышмаклар чишәләр.

– Түгәрәккә килү көннән көтеп торабыз. «Ватсап»та группабыз бар, шуннан хәбәрләшә-хәбәрләшә көн буе әзерләнәбез, – дип елмая Гакилә апа Нуретдинова. – Эшләгән вакытта бәйләргә, чигәргә вакыт булмады, 30 елдан соң кабат кулга бишенә алдык.

Гомере буе укытучы булып эшләгән Гакилә апа ай саен бер шигырь язып, түгәрәккә килгәч, аларны ятлап укып күрсәтә.

– Әниләр көне алдыннан җыелгач, Гакилә Рәмзия Габделхаковның «Әни килде» шигырен сөйләп елатты, – диде Флера апа. – Бергә җыелгач, баштагы бөтен начар уйлар тарала, җаңга тынычлык табабыз, күтәренке кәеф белән таралышабыз. Гомер буе бәйләсәм дә, моңа кадәр ыргак белән эшләгәнем юк иде.

Ахыры 5 нче биттә >

Автор фотосы

ГАИЛӘ ҖЫЛЫСЫ

Тукай

Тукай районының Таулы Дөреш авылында гомер итүче Розалия һәм Рәшид Фәритовлар бик күпләргә үрнәк. Алар ике кыз үстергән. Бүген инде оныклар сөяләр. Әти-әниләренә кылган игелекләрен инде хәзер үз балаларыннан күрәләр.

Әбит язмыш аларны кайда гына йөртмәгән. Әтисе Розалия ханымны Рәшидкә кияүгә бирергә теләмәгән. Әмма кияү үз сүзендә нык торган, Таулы Дөреш кызын Ереванга алып киткән.

– Иремнең әти-әнисе – Ютазы районыннан. Әтиебез Мисбах – бик укымышлы кеше. Ул һөнәре буенча монтажчы. Аны кая гына эшкә җибәрмәделәр. Хәтта Байконурда космодром төзүдә дә катнашкан ул. Аннары Ереванга китә. Соңгысында төпләнеп тә кала. Шунда биш балалары туа. Олы кызлары Вәсилә белән Рәшидне Чаллыга кайтарып җибәрәләр, – ди Розалия апа. – Әнкәй: «Миңа татар кызы, токмач басып аш пешерә торган килен кирәк», – дип әйткән булган икән. Гаилә корганда икебезгә дә 23әр яшь иде. Туган көннәребез дә бер генә ай аерма белән безнең. Шөкер, матур яшәргә тырыштык.

Әтисе Наил абый булачак кияүнең кыз сорарга үзе генә килүен бик аңлап бетерми. Әле бит татарчасы да юк. Өстәвенә кызын читкә алып китәргә тели. Әнә шуңа күрә ул башта риза булмый. Әмма кияү бабай күңеленә ачкыч ярата, кызны аңа кияүгә бирергә риза булалар. Тора-бара татарча сөйләшергә дә өйрәнә.

– Без башта Ереванда яшәдек. Әмма мин туган җиремне бик сагындым. Рәшид хәлемне аңлады, Чаллыга күчендек. Мин мәктәпкә эшкә урнаштым. Башлангыч сыйныфларда укыттым. Акрынлап тормыш җайланды. Әти-әниләрне ташламадык, Ереванга барып йөрдек. Рәшиднең ике туганы гүр иясе инде. Апасы белән сеңлесе исә Чаллыда эшләделәр. Икесе дә Чаллы егетләренә кияүгә чыкты. Монда гына яшәп калмадылар. Ростовка күчենделәр. Алар белән дә араларны суытмыйбыз. Кунакка йөрешеп торабыз. Йә алар кайта, йә без барабыз, – ди Розалия апа. – Әти-әнине дә олыгайган көннәрендә Чаллыга күчерә алдык. Алар безгә риза булып киттеләр. Үз әти-әнием исә сүз саен, гаиләне сакла, дип кенә тордылар. Әни бик акыллы иде безнең. Ир белән яшәү – сәнгать, дия торган иде. Тырыштык, ирне хөрмәт итеп, кадерләп, яратып яшәдек. Үзебезгә дә шундый мөнәсәбәт булды. Шөкер, инде балалар бәхетенә сөенәбез.

Гаилә архивыннан

Балалар дигәннән, Розалия апаның алар күп. Гомере буе мәктәптә укыткан укытучы бүген үзе белем биргән балаларга карап сөенеп яши. Аларның һәр уңышына чын күңелдән шатлана. Әле менә шушы көннәрдә генә Чаллы мәктәбендә укыткан баласы элемтәгә чыккан. Ул хәзер Мәскәүдә укый икән, укытучылары башлангыч белемең ныклы дип мактагач, укытучысын эзләп табып, аңа рәхмәтен җиткерергә булган. Укытучыга шул да җитә, укучысы өчен сөенеченнән йөзләре балкый. Ә узган атнада 30 ел элек мәктәпне тәмамлаган укучылары ресторанга чакырган. Розалия апа бу очрашуны искә алганда, күңеле тулып, елап та алды. Ә иң шатланганы – ул укыткан укучыларның барысы да матур яши. Гаиләле, тормышта үз юлларын тапканнар.

– Беренче сыйныфка 32 бала кабул иттем. Мәктәпне тәмамлаганда 18 калдылар. Очрашуга 16сы килгән иде. Пенсиядәге укытучы өчен шулай кунак итүләре зур мәртәбә булды инде. Мин ул чакта алар яшендә булганмын. Яшьлекләр искә төште, – ди Розалия апа. – Укытучыга хөрмәт кимеде, диючеләр дә бар. Бала күңелен яулый аласың икән, ул сине еллар узгач та онытмый. Ә бит лаеклы ялда булсаң да, күңел көтә. Аны бернишләтеп тә булмый. Әз генә булса да игътибар көтәсең. Ә мин исә рәхмәтлемен. Тормышыма, гаиләмә, укучыларыма. Аларның һәркайсы миңа бәхет бүләк итә. Ә бу хисләр миңа яшәр өчен көч бирә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«ЯШЬ БАРСА ДА, ЙӨРӘК УНҖИДЕДӘ!»

Чүпрәле

Шушы көннәрдә Яңа Чүпрәле авылында яшәүче Хәния Яхиева 95 яшен тутырды. Аны тәбрикләргә барлык якыннары җыелды.

Гаиләсе ишле икән юбилярның. Тормыш иптәше Абдулбарый белән алар биш балага гомер биргәннәр, балалары аларга 10 онык бүләк иткән, алар исә тагын 10 нәсел дәвамчысы белән куандырган.

Хәния әбинең хезмәт юлы колхозда, ашханәдә узган. 40 елдан артык ул аш-су әзерләгән. Абдулбарые да колхозда эшләгән. Икесе дә шушы җирдән, шушы туфрактан, читкә китеп бәхет эзләп йөрмәгәннәр, бар булганына шөкер итеп, кендек каны тамган җирдә яшәгәннәр.

Хәния әбинең пар канаты инде гүр иясе, төп нигезендә ул кызы белән яши. Татар хатын-кызларына гына хас булган оялчанлык, сабырлык белән, елмаеп, сорашканга җавап итеп кенә үткәннәре хакында сөйләде.

Әтисез, ятим үскән. Шуңа карамастан, күңелендәге игелекнең бер тамчысына да зарар китермәгән. Килгән кунакларга да, үзен олылаган бала-оныкларына да олы рәхмәтләрен укыды Хәния әби.

Хәния апаның дүрт баласы Яңа Чүпрәледә гомер итәләр, бер улы Ульяндa яши.

Олы юбилей бәйрәмен исә Хәния апа улы Җәмиләндә кунакта вакытында каршылады.

Автор фотосы

– Безнең әни – авыз эче тулы кан булса да төкерми торган, зарлануны белмәгән кеше. Атна ахырында исә балалар белән төп йортка чыгабыз. Әни мунча яга. Бер-бер артлы барыбыз да юынабыз. Үзенә юынырга җылы су кала идеме икән, дип уйлыйм хәзер. Шулкадәр киң күңелле кеше ул, – ди килене Гөлинә апа.

Күңеле шундый киң, олы булганга, Аллаһы Тәгалә Хәния әбине озын гомер белән бүләкләгәндер дә. Әнисе һәм әбисе дә озак яшәгән: 96 һәм 103кә җитеп, бакыйлыкка күчкәннәр. Хәния апа үзе исә яше турында: «Яшь барса да, күңел һаман унҗидедә», – дип шаярта.

Гөлия ФӘИЗОВА

ҖИЛДӘН ҖИТЕЗ

Автор фотосы

Кукмара

Кыш көне рәхәтләндереп чаңгыда җилдерә, ә җәен исә роллерда йөгерә. Кукмарада яшәүче Равил абый Кәримуллинны күп яшьләргә үрнәк итеп куярлык. Лаеклы ялда булуына карамастан, хәрәкәттә – бәрәкәт, дип яши ул.

Равил абый спорт белән кечкенә чагыннан ук кызыксына. «Мин тумышым белән – Югары Казаклар авылыннан. Мәктәптә укыганда физкультураны ярата идем. Олыяз мәктәбендә укытучыбыз Валерий Вуколов булды, иң беренче ул спортка мәхәббәт тәрбияләде, ярышларга йөртте. Физкультура дәресе көнгә бер тапкыр гына булса да, башка сыйныфларга ияреп, аңа икешәр тапкыр керә идем. Башта спортның бөтен төре белән дә кызыксындым: футбол, теннис та уйнадым, гер дә күтәрдем… Ә аннан соң үзем өчен чаңгыны сайладым. Армиядә Монголия якларында хезмәт иттем. Кар булмагач, ике ел туктап торырга туры килде. Аннан кайткач, училищега мастер булып урнаштым, алга таба киез итек-киез комбинатында тракторда эшләдем. Билгеле, ул вакытларда чаңгыда сирәгрәк йөрелгәндер. Ә менә лаеклы ялга чыккач, бөтен буш вакытымны әлеге спорт төренә багышладым», – ди Равил абый.

Ул әле дә чаңгы ярышларында катнаша. Өйләренең бер як дивары аның медальләре белән бизәлгән.

– Спортта тырышлык та, үҗәтлек тә бик кирәк. Мәктәптә 7 нче сыйныфта укыган вакытта Кукмарага ярышка килдек. Шунда ахыргы урыннарның берсе минеке булды. Шулхәтле ачуым чыкты. Кайткач, ныклап шөгыльләнә башладым. Өйдән Янил мәктәбенә хәтле нәкъ 4 чакрым иде. Шул араны җәй көне йөгереп, кыш көне чаңгыда уздым. Физкультура укытучысы булу теләгем дә бар иде, мөмкинлек кенә чыкмады, – ди ул. – 1976 елларда уку йортының диварында «Безнең рекордлар» дигән стенд бар иде. Анда барлык спорт төрләре буенча студентлар ирешкән рекордлар теркәлеп барды. Шундагы ике күрсәткечне мин яңарттым. 5 чакрым араны 16 минут 56 секундта һәм 10 чакрымны 36 минут 34 секундта чаңгыда шуып, үзебезнең студентлар арасында рекорд куйдым. Тик шунысы кызганыч: бу вакытлардан соң 48 ел узган, әмма мине куып җитә алган кеше юк әле. Ә үзем бу күрсәткечләрне күптән уздым инде.

Үзе генә түгел, чаңгыда 60 яшьтән узган 6 кеше бергә йөриләр икән. Чаңгыда йөргән вакытта иркенлек, рәхәтлек сизә, саф һава сулап, матур табигать белән хозурлана чаңгычы. Шуңа күрә яшьләргә диван-креслолардан торырга һәм спорт белән шөгыльләнә башларга киңәш итә ул.

«Бервакыт егылып, кара канга батып кайтканнан соң, башка роллерга басмас инде, дигән идем. Кая ул, әле җәрәхәте төзәлеп тә бетмәгән иде, тагын киемнәрен күтәреп чыгып китте», – дип сүзгә кушыла тормыш иптәше Лидия апа.

– Без роллерда Иске Йорт авылы янындагы юлда йөрибез. Берсендә таулы җирдән төшкәндә, каршыга көтү очрады. Роллер белән таудан төшкән вакытта туктап калып булмый бит, юл читендәге ташларга егылдым. Әмма бу гына әлеге спорт төренә мәхәббәтемне киметә алмады. Шуңа күрә алга таба Кукмарада роллер трассасы төзелсә, бик яхшы булыр, сөенер идек, – ди Равил абый.

Ул тормыш иптәше белән Янилдә укыган вакытта таныша, Лидия апа шул авылныкы икән. Алар бергәләп концертлар куеп йөргән чакларын сагынып искә алдылар.

«Мин гармун уйныйм, ул җырлый иде», – ди Равил абый, хатирәләргә бирелеп. Лидия апа да, тормыш иптәше кебек, спортны үз итә, көн саен булмаса да, аның белән бергә чаңгыда йөрергә чыга, иренә һәрвакыт теләктәшлек күрсәтә.

Ризилә КОРБАНОВА

КУЛДА – ГАРМУН, КҮҢЕЛДӘН МОҢ АГА

Апас

Кызыл Тау якларында җыр-моңга гашыйк халык яши. Җырчылары, гармунчылары белән дә данлыклы ул. Илсөяр апа Сафина да 4 яшьтә гармунда уйнарга өйрәнгән.

– Әтием Вазыйхҗан, абыем Насыйх Миңнегалиевлар өздереп гармунда уйныйлар. Аларга ияреп, мин дә кечкенәдән кулыма гармун алдым. Гаиләдә барыбызның да күңелендә моң яши. Әтинең кечкенәдән урындыкка бастырып җырлатканнары истә калган. Безнең гаиләдә һәр кич концерт кую белән тәгәлләнә иде, – ди ул.

Илсөяр апа иң беренче булып «Яшь гомер» җырының көен суза. Кечкенә бармаклары гармун телләрендә биеп, үзеннән-үзе матур көйләр чыгара. Аннан икенчесе, өченчесе… Шатлыклары булса да күңеленнән моң булып түгелә, борчулары булса да куллары гармунга үрелә.

– Без биш туган – 4 кыз, 1 малай үстек. Әниебез бик яшьли арабыздан китте. Ул вакытта миңа – 4, сеңлемә 1 яшь кенә иде әле. Безне әти һәм әтиебез ягыннан дәү әниебез үстерде. Мин 9 нчы класста укыганда әти кабат өйләнде. Бик матур яшәделәр, – дип еракта калган булса да, бүген дә йөрәгендә сакланган хатирәләр белән дә уртаклаша Илсөяр апа.

Әтисе Вазыйхҗан абый моннан 8 ел элек тормыштагы ярын кабат югалтып, бүген ялгызы яши. Җәйләрен Илсөяр апа гаиләсендә, кышларын Чистай шәһәрендә яшәүче улы Насыйх янында үткәрә ул. Кайда гына, ничә яшьтә генә булса да, ул гармуныннан аерылырга теләми, бик яратып җырлар тыңлый.

Илсөяр апаның сәхнәдән төшкәне юк. Тормыш иптәше Рашат абый да – мәдәният хезмәткәре. Авылда узган бер генә кичә дә Илсөяр апаның җыр-моңнарыннан башка узмый. Районкүләм чараларда да ул – еш кунак. Үзе уйный, үзе җырлый.

– Сәхнәгә чыккач, иңнәремдәге гармунның авырлыгы да онытыла, – ди ул.

Илсөяр апа 25 ел гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган. Кызыл Тау мәктәбенең тәҗрибәле химия-биология укытучысы ул. Мәктәптә музыка дәресләре дә алып бара. Укучылар да, үзенең балалары да сәнгатькә, сәхнәгә тартыла. Бик күпләргә үрнәк булып яши Илсөяр апа. Күңеле тулы сагыш булса да, ул аны җырлары белән тарата. Гармунын алып уйнап җибәрсә, дөнья тагын да матурлана.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

Автор фотосы

Автор фотосы

ШАКИРОВЛАР ЭЗЕ

Мамадыш

Районыбызның Түбән Ушма авылында хезмәтләре белән дан казанган гаилә династияләре күп. Өч бертуган – Габделхак, Мөхәммәтҗан, Мөхәммәтсалих Шакировлар авылыбыз данын еракларга таратты. Ике абыйлары гомерләрен авыл хуҗалыгына багышласа, кечеләре мәгарифкә хезмәт итте.

Габделхак Шакир улы, 1936 елда туды булмаган урта мәктәпне тәмамлауга, 15 яшеннән тракторга утыра, ә 19 яше тулгач, 1940 елда Совет Армиясе сафларына алына. Дингезче егет аннан бары тик 1948 елда гына кайта ала. 1945 елда Япониягә каршы сугышта катнашырга туры килә аңа.

Армия хезмәтен, сугыш кырын күреп кайткан егетне «Мамадыш» совхозына партия оешмасы секретаре итеп куялар, шул елларда партия мәктәбендә укып белем ала. Оештыру сәләте көчле булган Габделхакны 1955 елда Мамадыш районы партия оешмасы секретаре итеп билгеләләр, ә тагын бер елдан район башкарма комитеты рәисе була. Илленче еллар ахырыннан үзен тулысы белән авыл хуҗалыгына багышлый өлкән Шакиров. «Прикамский», «Родина» совхозлары директоры да була. Ә гомеренең соңгы елларында Түбән Кама районының иң зур «Түбән Кама» совхозын җитәкли. Таләпчәнлеге белән аерылып торса да, кул астындагыларның хөрмәтен тоеп яши. Тырыш хезмәт эзсез узмый, күпсанлы бүләкләр арасында Ленин орденының (1966, 1979) гына да икәү булуын әйтеп китү дә җитә торгандыр.

Габделхак абый кайда гына эшләсә дә, туган авылы, якташлары белән араны өзми, кендек каны тамган газиз туфрагына сагынып-җирсеп кайта иде. Аңа һәр ерганак, һәр буразна таныш бит. Инде бик күпләргә таныш «Гармун алыйк әле, дускай!» җырының сүзләре дә шул вакытта тугандыр.

РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Габделхак абый Шакиров белән еш күрешә идек, яшәеш, киләчәк турында күп сөйләштек. Бала чагында бик күп авырлыклар күрергә туры килә аңа. Шулар турында сөйләшкәндә әллә уйлап, әллә ялгыш, бер сорау бирдем: «Әгәр тук тормышта яшәгән булсагыз, сез нинди кеше булыр идегез?» Җавабы моңлый булды: «Миңа бу сорауны бирүче күп булды, җавап бирү авыр, шулай да хәзерге характерлы, кешеләрне аңлый торган, аларның тормышларын кайгырта торган кеше булыр идем, дип өздереп әйтә алмыйм… Тук кешенең күңеле шук була, дип әйтә халык…»

Мөхәммәтҗан Шакиров та абыйсы эзеннән бара. Ул тракторчы та, хисапчы да, агроном да, авыл советы рәисе дә була. Үзенең 30 ел гомерен Түбән Ушма, Урнәк, Хафизовка авылларын берләштергән «Кызыл флаг» колхозында колхоз рәисе булуга багышлый. Республика гына түгел, хәтта Россия күләмендә күренекле хуҗалыкка әверелә ул. Республикада иң күп икмәк тә, иң күп сөт тә шунда җитештерелә. Үз авылы халкы күңелендә тирән эз калдырган Мөхәммәтҗан абыйга авыл халкы бүген дә рәхмәтле, аның исемен мәңгеләштерү максатыннан Түбән Ушма гомуми урта белем мәктәбенә Мөхәммәтҗан Шакиров исеме бирелде. Моннан да зур хөрмәт була аламыни?!

Кече энеләре Мөхәммәтсалих Шакир улы да язмышын туган авылы белән бәйли – укытучылык эшен сайлый. Заманы өчен районның иң олы мәктәпләреннән булган Түбән Ушма мәктәбендә озак еллар директор була, туган авылы балаларына тарих фәнен укыта. Укыту-тәрбия эшләренең куелышы буенча бу мәктәп районда алдынгылар сафында була. Ике катлы агач мәктәп урынына заманча проект белән яңа мәктәп төзелә, мәктәпнең матди-техник базасы яңартыла, үз эшләренең осталары булган укытучылар коллективы тупланы.

Түбән Ушма тарихында тирән эз калдырган бертуган Шакировлар инде арабызда түгел. Ләкин хезмәтләре белән кеше күңелендә тирән эз калдырган әлеге олпат ирләрне хәтерләүчеләр күп әле.

Хәлим СӘЛАХОВ.
Түбән Ушма авылы

АВЫЛЫМ ДИП ЯШИ

Тукай

Иске Дөреш авылында туып-үскән Гыйздулла абый Вәлиуллин хакында сөйлисем килде. Ул 1949 елның 8 февралендә Галимулла абзый белән Хәдичә апа гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга аваз сала.

Сигезьеллык мәктәпне туган авылында, 9–10 нчы сыйныфларны Теләнче Тамак урта мәктәбендә көмеш медальгә тәмамлап, Алабуга дәүләт педагогия институтына, физика-математика факультетына укырга керә егет. Армия хезмәтен үтәп, яңадан туган авылына физика-математика фәннәре укытырга кайта ул. Мәктәптә тәҗрибә туплаган ир-егетне 1990 елда авыл советы рәисе итеп сайлыйлар. Бу җаваплы вазыйфада 20 ел хезмәт итә ул. Авылда чисталык һәм тәртип булсын, халык матур һәм җайлы яшәсен өчен, бар көчен куя ул.

Татар халкының бик тирән мәгънәле әйтеме бар: «Эшләгәнгә эш язган». Гыйздулла абыйның да хезмәт чорына катлаулы, җаваплы, күп хезмәт сорый торган күләмле эш – авылларны газлаштыру туры килә. Аның тынгысызлыгы, төгәл фән укытучысы буларак, исәп-хисапны белеп эшләве нәтиҗәсендә 2002–2004 елларда авыл җирлеге карамагындагы 5 авылда да газ плитәләре кабына. Күпкатлы ике йорт, мәдәният йорты, мәктәп газ белән җылытуга күчә. Яшьләр программасы белән йортлар салу да шушы чорга туры килә. Авыллар арасындагы юлларны төзекләндерү, яңа төзелгән урамнарга су кертү һәм башка зур эшләр башкарыла.

Әйе, зур ихтыяр көче, тынгысызлык, җаваплылык, җитезлек белән шул ук вакытта үҗәтлек тә сорый торган эшләр башкарылган. Туган авылын, дип яшәү, авылдашларына булган ихтирам хисе ярдәм иткән, көч биргәндер аңа. Әлбәттә, тормыш иптәше – тарих, җәмгыять белеме укытучысы, күпсанлы мактау кәгазьләре, медальләр иясе Нурия апаның да ярдәме бәяләп бетергесез.

Гыйздулла абый белән Нурия апаның өч баласы да югары белем ала. Үзләре тормыш корып, әби-бабайга сөеп туймаслык оныклар үстерәләр. Эти-әниләре оясына кайтып, Нурия апаның тәмле ашлары, кабарып пешкән камыр ризыклары белән сыйланып, кадерхөрмәт күрсәтеп китеп тә баралар.

Гыйздулла абый Вәлиуллин – кабатланмас моң иясе. Үзешчән башкаручыларның «Балкыш» фестивалендә 4 тапкыр лауреат исемен яулаган кеше.

Һәр көн авылыбызның мәчет манарасыннан аның моңлы да, аһәңле дә тавыш белән азан әйтүе ишетелә. Авылыбызның хәзрәте дә әле ул. Менә шундый якты, игелекле кеше яши арабызда. Аллаһы Тәгалә аңа исәнлек-саулык белән озын гомер бирсен.

Автор фотосы

Ләйсән МИННӘХМӘТОВА

БЕР ТЕЛЕМ ИПИ КАДЕРЕ

Казан

Казанда Бөек Ватан сугышында һәм махсус хәрби операциядә катнашучы батырларны үз эченә алган «Геройлар безнең арада» дип аталган күчмә күргәзмә ачылды. Аны Татарстанның Ветераннар берлеге белән ДОСААФ оешмасы әзерләгән.

Оештыручылар әйтүенчә, әлеге күргәзмә бөтен Татарстанны әйләнеп чыгачак. ДОСААФ идарәсе рәисе Сергей Старостин фикеренчә, без батырларны онытырга тиеш түгел.

– СВОда күпме егетләребез батырлык кыла. Без алар белән горурланырга тиеш. Алар Ватаныбызны саклый. Егетләрнең һәр батырлыгы еллар дәвамында сөйләнәчәк, тарихка кереп калачак. Безнең бурыч – әлеге вакыйгаларны һәркемгә җиткерү, – ди ул.

Татарстанның Ветераннар берлеге рәисе Александр Бородин исә, исә тантанада катнашкан яшь армиячеләргә җылы сүзләрен җиткерде.

– Сезнең алда Ватанны ярату, саклау бурычы тора. Сез – безнең киләчәк, – диде ул. Россия Герое Рәсим Баксиков та яшьләргә үз киңәшен бирде.

– Ватанпәрвәрлек күңел хисе генә түгел. Сез хәзердән үк алдыгызда торган зур бурычны аңларга тиеш. Илебезне яратып яшәргә кирәк, – ди ул. – Чит илләрнең йогынтысы бик зур. Алар сәясәткә дә, яшьләр тормышына да килеп керде инде. Әмма без үзебез булып калырга тиеш. Киләчәктә нинди генә юл сайласагыз да, республикабыз өчен кирәкле кешеләр булыгыз.

Чарага Ленинград камалышын үзе кичергән 91 яшьлек профессор Вильям Барабанов (рәсемдә) белән Валентина Тарасюк та килгән иде.

– Сугыш башланганда, миңа 8 яшь иде. 22 июнь – ял көне, без дачада идек. Апам Ариадна белән мине Ленинградка алып килделәр. Әтием заводта эшли, әнием хастаханәдә психиатр иде. Сентябрьдә блокада башланды. Авылларда яшәүчеләр шәһәргә килеп бетте. Безне гел бомбага тоттылар, – дип искә ала ул авыр елларны



Вильям Барабанов. – Ачлык килде. Кешеләр атлап барган җирләреннән егылып үлә иде. Без ничек булдыра алабыз, шулай җылындык. Мичкә ни генә якмадык. Бер бүлмәгә җыелып, җиһазларны, ишекләрне яга идек. Карточка белән ашадык. Тәүлегенә 125 грамм ипи бирерләр иде. Нәрсә ашап була, шуны ашадык. Үләсе килми бит! Дивардагы обойларны ябыштырган җилемнән аш пешерер идек. Ул чакта бит аның составында крахмал белән он иде.

125 грамм ипи дә тараттылар очрашуда. Авыр елларны искә алу, ризык кадерен белү өчен эшләделәр моны.

– Кич буе ипи эзләдек. Кара булсын дидем. Аны 125 грамм итеп кистем. Аның янына блокада ипиенең ни икәнен аңлатып, язу куйдым, – ди волонтер Хөрия Хәлитова. – Без тарихны онытмаска тиеш. Шөкер, яшьләр дә бу хакта белеп үсә. Безнең максат та шул – үткәннәрне онытмау.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

900гә якын көн һәм төнгә сузылган блокада вакытында дошман шәһәргә 150 мең снаряд, 102 мең яндыргыч бомба һәм 5 мең чамасы фугас – зур җимергеч көчкә ия бомба ташлый. Камалыш чорында шәһәр 1 млн чамасы югалтуларга дучар була, күп кеше ачтан үлә. Халык ополчениесе һәм регуляр гаскәрләр шәһәрнең оборона комитеты җитәкчелегендә дошманга каршы оешкан төстә көрәшә. 1941 елның 22 ноябрендә Ладога күле боз аша Ленинградка ярдәм килә. Боз өстеннән үткән әлеге юл «Тормыш юлы» дип атала.

Автор фотосы

ЭШ ҺӘМ АШ

Кукмара

«Миңа ияреп барыгыз, сезгә ипи ашатачакмын», – диген ул «Восток» колхозының хезмәт коллективы белән үткән беренче җыелышында. Чыннан да, Гафият Гарифуллин хуҗалыкны күтәрә алган, халыкны ипиле дә, акчалы да иткән. Ул җитәкләгән чорда колхоз сөт җитештерү буенча республикада алдынгы урыннарга чыга.

Ядегәр авылы мәдәният йортында ТАССРның атказанган агрономы, РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, легендар шәхес Гафият Гарифуллинның 100 еллыгына багышланган тантаналы чара узды. Бөек Ватан сугышы ветераны, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Мактау билгесе» орденнары, медальләр белән бүләкләнгән, исеме чын мәгънәсендә зур хәрефләрдән язылырга тиешле Гафият абый үз вакытында районыбызның үсемлекчелек һәм терлекчелек үсешенә зур өлеш керткән. Ул җитәкләгән елларда «Восток» колхозында холмогор токымлы иң яхшы сыер көтүе булдырыла, 1 сыердан сөт саву 1845дән 4200 килограммга күтәрелә.

– «Восток» хуҗалыгына мин сигез ел эшләдем һәм ышаныч белән әйтә алам: Гафият Гарифулла улының авыл хуҗалыгын интенсивлаштыру буенча тәвәккәл адымнары безнең районның алга таба социаль-икътисадый үсешенә нык нигез салды, – диде район башлыгы Сергей Димитриев.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова, авылдашлары, хезмәттәшләре якташыбыз турындагы җылы истәлекләре белән уртаклашты. Чыннан да, ул җитәкче генә түгел, ә күпләр өчен киңәшче дә булган.

Легендар шәхестән идарә «штурвал»ын кабул иткән Илгизәр Ибраһимов сүзләренчә, Гафият Гарифулла улы җитәкчелек иткән елларда алдынгы хуҗалык буларак биргегә тәҗрибә уртаклашу өчен килгәннәр. «Минем өчен остаз гына түгел, ә профессиональлек өлгесе дә иде», – ди ул.

– Гафият Гарифулла улы җитәкчелегендә мин 19 ел эшләдем. Үзенең таләпчәнлегенә һәм кайвакыт кырысылыгына карамастан, ул ярдәмчел һәм игелекле җитәкче булды, – диде Разыя Сәмиева. – Бер кызыклы очрак искә төшә. Гадәттә, иртәнге нәрәткә кадәр ул колхоз территориясен әйләнеп чыгарга өлгерә иде. Еш кына төнге рейдларга чыга. Бервакыт көтүгә килә һәм көтүчеләрне йоклап яткан килеш күрә, аннан соң механизаторлар янына басуга бара, анда да – шундый ук хәл. Гафият Гарифуллин түзми – тракторны кабыза. Механизаторларның ничек курыкканын чамалыйсыздыр?!

…«Восток» колхозы тормышын һәм казанышларын күрсәткән тарихи кадрларны һәркем кызыксынып карады. Очрашу, күңелдә җылы тәэсирләр калдырып, бер сулышта узды.

Шушы көннәрдә Ядегәр урта мәктәбе базасында колхозның элеккеге рәисенең 100 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция да узды, анда Гарифуллиннар гаиләсенең шәҗәрәсе дә тәкъдим ителде.

Йолдыз ГЫЙМАДИЕВА

Җырлый-җырлый бәйлиләр

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гөлнәзирә Биктаһирова белән Флера Минхәерова түгәрәк эшли башлаганнан бирле бирдә. Яшь вакытлан ук башлык, шарф кына түгел, свитерлар, итәкләр дә бәйләгән осталарга яңа әйберләр өйрәнүнең авырлыгы юк. Гөлнәзирә апа картиналар да чигә. Аның бу иҗат җимешләре ике дистәдән дә артык.

Оста куллар кульяулык та чиккәннәр, башмаклар да бәйләгәннәр. Алар кул эшләрен монда башлыйлар һәм өйдә дәвам итәләр. Кабат җыелгач, бер-берсенең эшенә карыйлар, ялгышлар, хаталар тапсалар, аны төзәтеп җибәрәләр. Кыскасы, бер гаилә кебек, узара ярдәмләшеп эшлиләр.

– Әлфинә безгә шөгыльне табып кына тора, ей эшләре дә бирә, – дип шаяртып алды Разыя апа Сөләйманова. – Ул барын да аңлата, үзе күрсәтеп, видеолар да җибәрә.

Кадрия ГАМИРОВА

ИР – БАШ, ХАТЫН – МУЕН

Арча

Мәмсә авылында яшәүче Рузалия һәм Камил Насыйбуллиннарны Арча районында белмәгән кеше сирәктер. Бу гаиләнең иң зур байлыгы – тырыш хезмәтләре, горурланып сөйләрлек балалары.

– Мин булачак иремә Камилнең сеңлесе Нурания нең класс җитәкчесе идем, – дип сөйли Иске Йорт авылында туып-үскән Рузалия. – Беренче тапкыр аларның өенә атлап кергәч, әнисе бик җылы каршылады. Иркенләп сөйләшеп тә утырдык. 2 улы, 4 кызы бар икән. Мин китәргә кузгала башлагач, «Менә бу – минем олы улым Камил, Владивостокта армия хезмәте үтә», – дип рәсемен күрсәтте. Мин: «Улыгыз бик чибәр икән, исән-сау хезмәт итеп кайтсын», – дип саубуллаштым. Шушы йортка килен булып төшәрмен дип кем уйлаган!

Аларны комсомол таныштыра. Камил 1972 елда армиядән кайта. Колхозда баш зоотехник булып эшли башлый. Ә Рузалия – колхозның комсомол оешмасы секретаре. Камилне дә комсомол комитетына сайлыйлар. Шуннан болар дуслашып китә. Дуслык мәхәббәткә әверелә һәм яшьләр гаилә кора.

Рузалия сөйләгәннәрне тыңлап утыру миңа бер рәхәтлек бирде. 50 ел бер-берсенә ышанычлы, тугрылыклы пар булып, туганнары, олыларның ихтирамын яулап, гаилә җылысын саклап яши алар.

Гаилә башлыгы, терәк-тоткасы – әти кеше, аның ярдәменнән башка хатын-кызга бик авырга туры киләчәк иде. Камил гаҗәеп акыллы, намуслы, кешелекле, ярдәмчел. Тормыш иткәндә төпле, акыллы кешең булу – олы бәхет ул. Яшьләрнең хәзер каенаналары белән бик яшисеәре килми. Әмма ата-ана нигезен кемдер сакларга тиештер бит. Ә Рузалия белән Камил төп нигездән, әти-әни янынан китәргә уйламыйлар да. Алар өйләнешкән вакытта каенанасына нибары 46 яшь була. Гаиләдә алты бала, өчесе әле мәктәптә укый. Рузалия иренең туганнарын да якын күрә, аларны әле дә сагынып көтеп ала.

Рузалия белән Камил өч бала тәрбияләп үстерә. Барысы да югары белем ала. Әби-бабай тәрбиясе алып, тәртипле булып үсәләр. «Без эштән кайтып кермәдек, балаларны әткәй белән әнкәй карап үстерделәр, – дип сөйли Рузалия. – Дәү әтиләре, малайларны үз тирәсендә кайнаштырып, балта-чүкеч тотарга, хезмәткә өйрәтте. Дәү әниләре балаларны яратып-сөеп тәрбияләп үстерде, җил-яңгыр тидермәде. Әнкәй бик тә киң күңелле, сабыр, юмарт, эшчән булды. Аның белән 41 ел бергә гомер кичердек. Мин аларга бик тә рәхмәтле».

Рузалия ханым – абруйлы укытучы һәм җитәкче. 12 ел Ташкичү мәктәбендә директор булып эшләде. Югары категорияле җитәкче, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы. Бөтен гомерен мәгарифкә багышлаган остаз-укытучы. Район һәм республика матбугатында мәкаләләре чыгып килә. Җиде китап авторы. Актив җәмәгать эшлеклесе. 18 ел Ташкичү авыл җирлеге ветераннар советы рәисе, 13 ел «Өммегөлсем» фольклор ансамбле җитәкчесе булды. Ул – «Балкыш» фестивале лауреаты, «Ел хатын-кызы» республика бәйгесенең зона этабы җиңүчесе дә әле. Һәрвакыт кыю, тәвәккәл, гади һәм гадел була белде.

Габделбәр САБИРОВ,
Яңа Кенәр авылы
ветераннар советы рәисе

ОЧРАШЫРГА СӘБӘП БАРМЫ?

Балтач

Бу араларда авыл, район мәктәпләрендә элекке чыгарылыш укучылары белән очрашулар бара. Безнең мәктәптә бер-ара алар тукталып торган иде. Үткән ел бу чара яңартылгач, бик сөендек (мәктәп тәмамлаганга былтыр кырык ел иде). Быелгысы да бик матур үткән. Әмма сүзем әлегә чара турында түгел.

Быелгы чара инде әзерләнеп бетте, дигәндә генә, өлкән яшьтә булса да, әле авыл тормышында бик актив катнашучы Ильяс абый Әхмәтҗанов укытучыларга: «Мәктәп тәмамлаганнарына 55 ел тулганнарны бәйрәмгә чакыргансыз икән, безгә дә быел 60 ел тула бит, безне дә чакырыгыз әле», – дигән. Оештыручыларга шул җитә кала. Әле бит мәктәп архивында аларның журналы да сакланмаган, фотолары гына түгел, исемлек тә юк. Әмма ул буын бүгенгәчә шулкадәр актив: исемлек тә, фотолар да табыла – бер көн эчендә бөтенесен үзләре әзерләп китерәләр. Бәйрәмгә дә киләләр. Олпат кунаклар булырак, урыннары да түрдән була.

Бу вакыйга моннан унатлы ел элек булган бер хатирәне яңартты. Ул чакта минем мәктәп тәмамлавыма 25 ел иде. Очрашуга чакыру кәгазе алгач, ниемә кирәк соң инде елына ике мәртәбә очрашу, җәй башында тагын оештырылачак бит, дип «дулап» алуым истә. Очрашуга бару уемда да юк иде. Тик фикеремне үзгәртергә бер телефон шалтыравы җитә калды.

Иртәгә очрашу дигән көнне иртүк әнинең сыйныфташы Иске Салавычтан Габделхак абый Латыйпов шалтыраткан иде (хәзер инде мәрхүм). Озак еллар колхозда партоешма секретаре булып эшләде, үз чорында эше бик макталды, югары бәяләнде. Кешеләр белән эшләү, аралашу дигәнне бу абыйның каныңа сеңгән иде. Эштән туктагач та, өйгә бикләнмәде ул, нәрсә әйтерләр, гаепләмәсләрме дип тормады, авылның өлкәннәре белән тиз арада уртак тел тапты, мәчетенә дә йөрде, җеназасына да, башкасына да.

Әле алай гына да түгел, авылның ветераннар советы рәисе булып, башка авыллардагы өлкәннәрнең дә хәлен белешеп шалтыратып торды. Барып, йөреп кайтырга да күп сорамый иде. Без дә инде аның әнинең хәлен белешеп шалтыратуына күнегеп беткән идек. Бу юлы исә шалтыратуның сәбәбе бөтенләй башка булып чыкты.

– Сине очрашуга чакырдыларамы? – дип сораган иде ул әниdән, хәл-әхвәл белешкәннән соң. – Яңгулга Марска да шалтыраткан идем, аны да чакырмаганнар. Кара әле, мәктәпне тәмамлауларына илле-илле биш ел тулганнарны чакырганнар, безне – юк. Безгә дә бит быел алтмыш ел тула…

Менә шул Габделхак абыйның «очрашуга чакырмадылар» дигән сүзе мине ул чакта уятып җибәргәндәй булган иде. Тагын бер мәртәбә үзебезнең битараф буын икәнлегебезгә инанып, егерме биш елга ничә очрашып, аларның берсенә генә булса да килергә вакыт тапмаган яшьтәшләр күплеге турында, сигезенче дистәнең уртасына җиткәннәр әле дә шулкадәр актив – кая чакырсалар, шунда барырга тырыша, без исә, аларның балалары, нигә шул дәрәҗәдә пассив соң, дип тә уйланган идем. Әле ул фикерем бер елдан соң – мәктәпнең туксан еллык юбилеенда катнашканнан соң тагын да ныгыган гына иде. Чөнки ул очрашуга да, башкаларындагы кебек үк, мәктәпнең «кичәге» укучыларына караганда өлкәнрәкләр күбрәк килгән иде.

…Егерме еллап вакыт үткән. Берни дә үзгәрмәгән. Безнең буында пассивлык, битарафлык дигәннәр әлегәчә сизелерлек күәтле. Безне шундый итеп тормыш үзе «әвәләде» дип, монысын да заманга сылтыйкмы инде? Алай дисән, бездән шактый соң – ун-унбиш еллар элек тәмамлаучылар белән дә шул ук хәл. Ә бу ике чор арасында упкындай аерма. Шул ук вакытта сигезенче дистәне куучылар, үтүчеләр әле дә актив. Алар да үзгәрмәгән…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

УЗГАНЫН ДА СИЗМӘДЕМ…

Мамадыш

Әниебез Шәһидә Гаффарова 1930 елда кызу урак өстендә дөньяга килгән. Авыр еллар – колхозлашу, Сталин репрессияләре, ачлы-туклы тормыш – башыннан барысы да уза.

Бала чагын да, яшьлеген дә сугыш урлый әнинең. Аналары бик тырыш, уңган булалар. Учка сыярлык булугa, печән җыялар. Урманнан кайтып кермиләр, «уфалла» арбасы белән кышка дип егерме бишәр юк куак әзерлиләр. Үз иңнәрендә күпме авырлыклар күтәрә алар. Ачмы син, тукмы, хәлле-хәлсезме – анысын уйлап торыш юк. Сугыш дигән нәрсә бөтен эшкә мәҗбүр итә. Нинди авыр эш бар, көчләре җитмәсә дә эшлиләр. Авылда бала-чага күп, ә эшләргә кеше юк. Картлар, әниләр генә. Апалары белән урагын да уралар, киндерен дә сугалар. Яклаучысыз кешеләргә бигрәк тә авыр була ул елларда.

Үсмер еллары урак урып, урман кисеп уза. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр хезмәт куялар. Үгезен дә, атын да җигәләр. Унбер яшеннән колхоз бригадасында эшли башлый әни. Ачлы-туклы килеш тилмереп җыйган ашлыкны, «фронт өчен» дип, көз көне Мамадышка илтеп тапшыралар. Маллар ач кала. Үзенә бер уч ашлык алсаң, төрмәгә илтеп ябалар.

Яз җиткәч, чәчәргә орлык юк. Көз көне кырып-себереп атларга төяп җибәргән орлыкны 25 км ераклыктагы район үзәгеннән чаналарга салып тартып алып кайталар. Колхоз атлары ачлыктан күтәрәмгә кала. Ат урынына сыер җигәләр. Владимирдан, Югары Ушмадан орлык ташыйлар.

Артык мал асрасаң, салым салып интектерәләр. Хайваннарың бар икән – вакытында син хөкүмәткә итен, йонын, йомыркасын, маен салым итеп тапшырасың. Түләмәсәң, авыл советыннан килеп, хайваныңны ирексезләп алып чыгып китәләр.

Ачлы-туклы еллар булса да, укырга тырыша алар. Аякта чабата, өскә киярга кием юк. Мәктәп салкын, кара савытына каз каурыен маныл-маныл язалар. 7 класс белем алгач, әни педучилищега укырга керә. Тик әбиебез авыргач, укырга насыйб булмый аңа, кире кайта, фермада сыерлар сава, бозаулар карый.

Авылыбызның уңган, алтын куллы егете Гасыймхан белән тормыш кора алар. Икесе дә ятим, үги каенана белән иске генә йортта яши башлыйлар. Әтиебезне армиягә алалар, әни өй төзи башлый. Өйне төзеп бетереп, рәхәтләнеп яшисе генә бит! Тик Гыйлемхан абый тугач, урак урырга барган җирдән әни бик каты авырып кайта. Югары Сон урманы кырыеннан бала арбасы тартып, көч-хәл белән кайтып җитә ул. Яшьли авыр эштә эшләү үзенекен итә. Ә аннары әти белән ат җигеп, колхоз эше өчен Мамадышка барырга чыккач, боз ярылып китеп, салкын суга төшеп китәләр. Әни шул салкында, боз булып катып, өйгә кайтып егыла. Икенче баласы Рафилне табып 7 ай узгач, урмәләп йөрүгә кала. Шуннан соң әти, самавырны сатып, больницага илтә. «Бер атна ят, дәвалан, кайтам дип әйтмә!» – дип калдырып кайтып китә. Бер атнага барган җирдән, ел ярым ята ул Сабаның Нырты диспансерында. Дүрт ел бүе пневмониядән, плевриттан дәрес дәвалаганнар, ә чынлыкта умыртка баганасына ук салкын тигән булган. Авыр операция кичерә, умыртка баганасын чистартып, ике кабыргасын кисеп алалар. Ел ярым, гел тормышча, урын өстендә ята ул. Аллаһка шөкер, безнең хакка исән кала.

Автор фотосы

«Таяк»ка эшләп, «1941–1945 нче еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәте өчен» медале белән бүләкләнеп тә, хезмәт кенәгәсе дә, инвалидлык таныклыгы да булмый әнинең. 24 яшеннән авырый башлап, 28 яшендә инвалид кала. Авырса да, тагын бер ул, бер кыз алып кайта. Барысы өчен рәхмәт, әнием, сиңа!

Рәзинә ГАФФАРОВА.
Норма авылы

Әбиләр өлеше

Зәй

Зәй районында 13 урында маскировка челтәрләре үрәләр. Бу эшне Урта Багражда да башлап җибәрделәр. Зур эшкә үз өлешен кертүчеләр арасында Анна тути Кондрабаева да бар. Күзләре начар күрсә дә, кулдан килгәнне эшләргә тырыша ул.

Автор фотосы

Өлешчә мобилизация буенча ир-егетләр ил сагына баса башлагач, Баграж җирлеге халкы районда беренчеләрдән булып хәрбиләргә ярдәм итү эшен оештырды. «Җирлегебездә яшәүче халык ничек булса да махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итәргә тырыша. Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә исемле посылкалар җибәрдек. Сарсаз-Баграж клубында госпитальләр өчен эске киемнәр тегәләр. Маскировка челтәрләренең хәрби зонада иң мөһим әйберләрнең берсе булуын аңлап, уртабагражлылар челтәр үрергә керешә», – ди Баграж җирлеге башлыгы Павел Минеев.

Клара ЕРМОЛАЕВА

Безнең Илья Григорьевич!

Мамадыш

Юл кырыеннан әкрен генә мәһабәт гәүдәле олпат ир заты атлый. Узып киткәч, ирексездән артка борылып карыйсың. Бу бит Урманчы мәктәбендә 40 ел гомерен яшь буын тәрбияләүгә, аларга аң-белем бирүгә багышлаган мөгаллим, шуның 33 елын мәктәп директоры вазыйфасында эшләгән шәхес – Волков Илья Григорьевич!

Менә ул икенче туган йортына әверелгән мәктәбе каршына җитә, адымнар тагын да салмаклана. Нинди уйлар икән башында? Шушы бер мизгел эчендә үзен – 1967 елда институт тәмамлаган егетне – Җәнлек совхозы урта мәктәбенә физика укытырга билгеләүләрен, билгесезлек куркыткан яңа урында беренче эш көнен хәтерендә яңарткандыр, мөгаен. Бөтен күңелен биреп эшләгән тырыш егетне тиз күреп алалар, 1968 елда аны директорның уку-укыту эшләре буенча урынбасары итеп куялар. Ә 1969 елда, аңа зур ышаныч белдереп, җитәкче дилбегәсен тапшыралар. Хезмәттәшләренең ышанычын аклап, шушы җаваплы йөкне 33 ел җигелеп тарта ул!

Илья Григорьевич үзен оста оештыручы, җитәкче итеп таныта. Мәктәбен мактаулы биеклекләргә күтәрде. Ул эшләгән чорда ике тапкыр яңа мәктәп бинаоары төзелде. Мәгарифтәге казанышлары өчен, аны район, республика күләмендә генә түгел, Мәскәүдә дә зурладылар. Хезмәтенә күрә бәяләр икән, дәрт-дәрман арткандай була, сулыш алулары иркенәеп китә.

Тормышының шушы мизгелләрен хәтердә яңартып, моңсу елмаеп, юлын дәвам итте. Кем генә очрамасын, барысы диярлек үзенең укучылары бит. Инде алар үзләре дә әти-әни генә түгел, әби-бабай булганнар, оныкларының күңелләрен күреп йөрүләре. Әнә берсе, кул биреп күрешкәч, мыек астыннан гына елмаеп, истәлекләр яңарта: «Мин сезнең кабинет ишегенең кайсы якка ачылганын беләм. Хәтерләмисездер инде, коридорда чабып йөргән җирдән дежур укытучы тотып алып, кабинетыгызга кертеп бастырды. Сез шунда ачуланмадыгыз да бит!.. Зурлар кебек сөйләшеп утырдык әле. Сезнең янга ни өчен кертүннәрен дә онытым. Ләкин шуны әйтим: минем кабат ул кабинетка кергәнем булмады. Шундый зур урында утырып та, мине тигез күреп сөйләшеп утыруыгыз олыгайтып җибәрдеме?.. Белмим, ләкин кабат сезнең йөзгә кызыллык китерәсем килмәде минем», – дип сүзен тәмамлап, саламәтлек теләп, юлын дәвам итте.

Хатын-кыз – хис кешесе бит инде ул. Очрашып исәнләшүгә, иң беренче итеп тышкы матурлыкны мактый башлыйлар: «Ооо, Илья Григорьевич, сезне еллар да үзгәртми. Әле дә егетләр кебек бит сез!» Бу сүзләрме?.. Бу сүзләр яшәргә көч бирә, авырлар онытыла. Ничек ташлап китәсең менә шундый тәмле телле, олы йөрәкле кешеләр яшәгән әкияттәй табигатьне? Үзе кебек, шушы мәктәпкә рус теле һәм әдәбияты укытырга билгеләнгән Розага өйләнә. Гаиләдә ике кыз, бер малай үстерәләр. Тормыш дәвам итә. Инде уллары Руслан – үзе бабай. Илья Григорьевичның 5 оныгы, бер оныкчыгы бар. Бүгенгесе белән бәхетле ул. Урманнан башны горур тотып узарга була.

Әмма кеше организмы корычтан түгел шул. Корыч та бөгелә. Лаеклы ялда, үзе шикелле үк тырыш умарта кортлары белән мәш килеп, оныкларга сөенеп, тәрлә яшәп ятканда, йөрәгенә катлаулы операция ясата Илья Григорьевич. Операциядән соң инде ничә еллар, хәрәкәттә – бәрәкәт дип, һәркөн урам әйләнеп кайта ул… Шул хәрәкәт яшәтә аны. Тормышта авыр сынаулар аша үтеп, бүгенгегә килеп җиткән икән, димәк, Җирдә әле аның миссиясе үтәлеп бетмәгән, ул әле укытучы буларак та, остаз буларак та яшь буынга бик кирәк шәхес!

Флюра ГЫЙМАДИЕВА